КЕСӘ КАЛЫНАЙТУ

2024 елдан илдә озак вакытка исәпләнгән акча саклау программасы эшли башлаячак

> 5

ТАРТУ КӨЧЕ

Алабуга районының Көек авылында кышын нибары бер кеше кала

> 6

СҮЗЕ КАЛДЫ

Якыннары, дуслары, иҗатташлары, якташлары Роберт Миңнулинны сагынып искә алды, истәлекләре белән бүлеште

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 111 (29078) | Җомга | 4 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАБИГАТЬ САТАШТЫ

КИЛӘЧӘКТӘ ҺАВА ТОРЫШЫННАН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

Узган атнаның шимбәсе әле бүген дә күңелгә тынгылык бирми. Гадәти җәйге яшенле яңгыры белән генә узып китәр төсле тоелган кара болыт коточкыч давыл алып килгән булып чыкты. Күпме гомерләрне өздә, кемнәрнедер йортсыз калдырды, күп кешенең хуҗалыгына, машиналарына зыян салды ул. Белгечләр исә, мондый давыллар әле тагын кабатланачак, ул гына да түгел, гадәти күренешкә әвереләчәк, дип кисәтә.

> 7

АТНАГА ӨЧ МӘРТӘБӘ ЧЫГАБЫЗ

Август аеннан «Ватаным Татарстан» газетасы атнага өч мәртәбә чыга башлый. Ул сишәмбе, чәршәмбе һәм җомга дөнья күрәчәк.

Шимбә саны чыкмаса да, газетабызның күләме кимеми. Чөнки сишәмбе саны элеккечә 4 түгел, ә 8 битле булып чыга башлый. Әлеге үзгәрешләр укучыларыбыз өчен тагын да кызыклырак һәм мәгълүматлырак газета чыгарырга мөмкинлек бирер дип өметләнәбез. Журналистларыбыз фикерле, вакыйгалар агымында әһәмиятен югалтмый торган язмаларны күбрәк әзерләячәк. Моннан тыш, газетабызның сайтын да камилләштерергә ниятлибез.

Кадерле укучыларыбыз, сездән язмалар һәм киңәш-тәкъдимнәр көтәбез. Бергә булыйк! «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга беркайчан да соң түгел. Һәр айның 18енә кадәр язылсагыз, киләсе айдан ул өегезгә килеп торачак.

Ишетми калмагыз

Татарстан кырларыннан җыеп алынган быелгы уңыш күләме 1 миллион тоннадан артып китте. Шул уңайдан Татарстан Рәисе республика игенчеләренә рәхмәт әйтте. Уртача уңыш гектарыннан 28,4 центнерны тәшкил итә. 371 мең гектар мәйданда игеннәр суктырылган. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, әлегә иң мул уңыш Тәтеш, Кайбыч, Чүпрәле, Кама Тамагы, Яшел Үзән һәм Спас районы кырларыннан җыеп алынган. Әйтик, Тәтеш районында – бер гектардан уртача 43,8, Кайбычта – 39, Чүпрәледә 38,4 центнер уңыш чыга. Иң зур мәйданнар Аксубай, Әлки, Зәй, Яңа Чишмә районнарында суктырылган.

Россия Президенты Владимир Путин түрәләрнең үзебездә җитештерелгән автомобильләргә күчеп утыруын хуплады. «Министрлыклардан, ведомстволар, эшләр идарәсеннән чит ил машиналарын сатып алуны дәвам иттерү үтенече керде. Мин бу хәлгә нокта куелырга тиешлеген, илдәге барлык түрәләрнең үзебездә чыгарылган автомобильләрдә йөрергә тиешлеген әйттем», – дип белдерде ул.

Аның әйтүенчә, алар элеккегә караганда гадирәк машиналарда йөрергә мөмкин. «Ләкин моның бернинди дә начарлыгы юк. Киресенчә, әйбәтрәк тә. Түрәләрнең барысы да илебезнең автомобиль брендларын, башка продукциясен үстерүгә омтылу зарурилыгын аңларга тиеш. Тормыш сыйфатын яхшырту омтылышы да иң элек шуңа юнәлдерелергә тиеш», – диде Президент.

Беренче яртыеллыкта (гыйнвар – июнь айларында) Татарстан оешмаларында эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакы, узган елның шул ук чорындагы белән чагыштырганда 16,4 процентка артып, 57490 сумга җиткән. Росстат мәгълүматлары буенча, бу – Идел буе федераль округы төбәкләре арасында иң югары күрсәткеч.

Пермь крае (55612 сум) икенче урынга чыккан. Башкортстан – өченче (52658 сум), Самара (51898 сум) һәм Түбән Новгород өлкәләре (50804 сум) – дүртенче.

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Зәйдә юл буенда куелган плакатларга махсус хәрби операция геройларының фотолары урнаштырылган. Махсус хәрби операция барышында сержант Александр Ефимов һәм рядовой Илья Быков батырлык күрсәткәннәр. Александр Ефимов яраланган иптәшләрен куркыныч урыннан алып чыга. Ул «Батырлык өчен» медале белән бүләкләүгә тәкъдим ителә. Разведка подразделениесенең пилотсыз очу аппаратлары операторы, рядовой Илья Быков разведка барышында дошманның техникасын һәм сугышчыларын эзләп таба һәм аларны юкка чыгаруга өлеш кертә. Бу батырлыгы өчен ул Жуков медале белән бүләкләүгә тәкъдим ителә.
(«Зәй яңалыклары»)

Менделеевск

Яңа уку елында Менделеевскида яңа уку йорты – «Мирас» татар гимназиясе ачылачак. Хәзер гимназия урнашачак 7 нче мәктәптә төзекләндерү эшләре дәвам итә. Моның өчен 89 млн сум акча бүлеп бирелгән. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм республикада яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау, үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов гимназия турында мәгълүмат җиткерделәр. Уку йорты 264 баланы кабул итәчәк. Бирегә җомга мәктәбе, Габдулла Тукай исемендәге әдәби мәктәп, милли көрәш секциясе оештыру күздә тотыла.
(«Татар-информ»)

Алабуга

Гари авылында яңа мәчет ачылды. Гыйбадәтханәнең нигез ташы 2021 елда салынган иде. Бары руслар гына яшәү сәбәпле, революциягә кадәр дә, советлар чорыннан соң да авылда мәчет булмаган. Хәзерге вакытта Гарида яшәүче халыкның 52 проценты – татарлар. Киләчәктә мәчеттә дини дәресләр, балалар өчен рухи сәламәтләндерү курслары башлап җибәрү планлаштырыла. Хәзерге вакытта мәчеттә Рифкать хәзрәт Гарифуллин имамлык итә. Гари авылы мәчете – Алабуга мөхтәсибәтендә 12 нче гыйбадәтханә.
(Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте)

Мамадыш

12–13 августта Урта Кирмән авылы янында урнашкан «Кирмәнчек»тә беренче тапкыр «Гасырлар сугышы» бөтенроссия тарихи фестивале узачак. Тау башында урнашкан әлеге корылма X–XIV гасырларга – Болгар һәм Алтын Урда чорына карый. «Путешествие в прошлое» җәмгыяте башкарма директоры Алексей Кокурин сүзләренә караганда, бу тарихи урында Борынгы Рим сугышчылары һәм Иван Грозный чорындагы Россия патшалыгы укчыларының бәрелешләре күрсәтеләчәк. «Без чара кунакларына бу ике чорның бер-берсенә каршы бәрелешен тамаша кылу кызыклы булыр дигән нәтиҗәгә килдек», – ди ул. Моннан тыш, фестиваль кунаклары өчен концерт программасы, остаханәләр, лекцияләр, балалар мәйданчыклары да әзерләгәннәр.
(«Нократ»)

БАТЫР ЯУДА БЕЛЕНЕР

ТАТАРСТАН ЕГЕТЕНӘ РОССИЯ ГЕРОЕ ИСЕМЕ БИРЕЛДЕ

Россия Президенты Владимир Путин Мәскәү Кремлендә дәүләт бүләкләрен тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында Татарстаннан Ирек Мәгасумов та бар. Мамадышта туып-үскән подполковникка Россия Герое исеме бирелде.

kremlin.ru

Ирек 1988 елда Мамадышта туа. Гаиләдә бердәнбер бала була ул. Бик яшьли әтисез кала. «Үскәч, табиб булам», – дип хыялана егет. Әмма кинәт хәрби юнәлеш белән кызыксына башлый. Дөрес, башта медицина комиссиясен уза алмый. Башка табибларга мөрәҗәгать иткәч, алар башка карар чыгара: егет саусәламәт. Ирек бер ел Казан танк училищесында белем ала, аннары Ерак Көнчыгышка – Благовещенскидагы Рокоссовский исемендәге хәрби училищега күчә. Кызыл диплом белән укуын тәмамлый. Юргада хезмәт итә, шушында ук булачак хатыны Анна белән таныша. Хәзер Анна белән Ирек бер кыз үстерә.

Ирек Мәгасумов сайлап алган һөнәрен бик ярата, диләр. Шулай булмаса, махсус хәрби операциядә ул башланган көннән үк катнашмас та иде!

Хәрби хәрәкәтләр зонасында ничек кенә авыр булмасын, якыннары белән элемтәгә керми калмый Татарстан батыры. Әнисенә дә «Елап ятма анда, әни, барысы да яхшы, яратам» дигән сүзләрне сагыну хисенә төреп, еш җибәрә икән. Хәбәрләр карап, котқы таратырга, курку уятырга, борчылырга да ярамый дип кисәтә хәрби. Әнисе Нәзирә ханым да улы сүзен тыңлый – елап ятмый, нык булырга тырыша. Улының кыю йөрәкле икәнен белә бит ана! Герой исеме дә аңа юкка бирелмәгән. Хәер, әлегә аның нинди хәрби батырлык күрсәткәне билгесез. Ирек үзе бу хакта сөйләми калмас, дип ышаныйк.

Сүз уңаеннан, Россия Герое дигән мактаулы исемне тумышы белән Мамадыштан булган икенче егеткә бирәләр инде.

Махсус хәрби операциядә Россия Герое исеменә лаек булган Татарстан егетләре:
Дамир ИСЛАМОВ (2022)
Дамир ГЫЙЛЕМХАНОВ (2022)
Александр ЛАПИН (2022)
Андрей СОКОЛОВСКИЙ (2022)
Раил ГАБДРАХМАНОВ (2022)
Иван ДОДОСОВ (2022)
Олег СОРОКИН (2023)
Ирек Мәгасумов (2023)

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашучы подполковник Ирек Мәгасумовка мактаулы исем алуы белән котлап, телеграмма җибәрде:
«Хөрмәтле Ирек Илдус улы! Сезне чын күңелдән Россия Федерациясе Герое исеме бирелү белән котлыйм. Сугыш кырында Сез лаек булган бу югары исем, элек Казан танк училищесын тәмамлаган һөнәри биографиягезә кебек үк, Сезнең хәрби һәм гражданлык бурычыгызга тугрылыгызны, шулай ук зур шәхси батырлыгыгызны раслый, – диелә телеграммада. – Үз халкының батыр улы буларак, Сезнең белән чын күңелдән горурланам, әниегез Нәзирә Габделбәр кызына үз иленең батыр яклаучысын һәм чын патриотын тәрбияләгәне өчен зур хөрмәт сүзләре юллыйм. Сезгә, хөрмәтле Ирек Илдус улы, Россия даны өчен яңа казанышлар, барлык туганнарыгызга һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, ныклы ышаныч һәм һәрнәрсәдә иминлек телим».

Дәшмә, телефон!

Татарстанда яшәүчеләр мошенникларга көненә 8–10 миллион сум акча күчерә. «Кесәдә булганын гына чыгарып бирүдән тыш, банк саен бурычка акча җыеп, шуны үз куллары белән кырыгалдарларга тапшыралар», – дип гаҗәпләнүен яшерми хокук саклаучылар. Бәладән котылуның бердәнбер юлын да әйттеләр.

– Ел башыннан бирле читтән торып эш итүче мошенниклар республикада яшәүчеләрнең 2 миллиард сумнан артык акчасын урлаган. Мондый җинаятьләр саны артканнан-арта, – ди Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе җитәкчесе урынбасары Рәмис Газыймов. – Чагыштыру өчен: 2018 елда банк карталарыннан акча урлау һәм мошенниклыкның 1500 очрагы теркәлсә, быел алты айда гына да шундый 8852 җинаять кылынган. Барлык җинаятьләрнең 32 проценты телефон алдакчыларына туры килә. Шунысын да искәртик: бүген барыбыз да диярлек элемтә чараларыннан һәм электрон түләү системаларыннан файдаланабыз. Шуңа күрә кисәтеп бетерел тә булмый. Татарстанда яшәүчеләр уяурак булсын иде.

«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган чарада кат-кат әйттеләр: кешенең үз ризалыгыннан башка банк картасындагы яки хисап счетындагы акчага беркем дә тия алмый.

– Моңа бәйле бер генә җинаять очрагы да теркәлмәгән, – дип ассызыклады Рәмис Газыймов. – Халык үзе телефонның теге очындагы таныш түгел кешеләргә ышанып, карта турындагы мәгълүматны әйтә, смс-хәбәрдәге кодны укый. Алай гына да түгел, банкка барып, кредит та рәсмиләштерәләр әле. Бәладән котылуның бердәнбер юлы – шикле кешеләр белән сөйләшмәскә, телефонны шунда ук сүндереп куярга кирәк.

Идарә җитәкчесе урынбасары мошенниклыкка бәйле иң киң таралган очракларны да атады. Хәер, алар барыбызга да билгеле инде. Әмма нәтиҗәсе генә күренми, дип уфтана хокук саклаучылар.

Читтән торып алдау очракларының 40 проценты ялган банк хезмәткәрләренә туры килә. «Элек мошенниклар үзләрен кредит оешмасыннан дип кенә таныштырса, хәзер «полиция хезмәткәре» белән дә тоташтыралар. Яшенә, белеменә, эш урынына карамастан, халык алдакчылар кармагына эләгә», – ди Рәмис Газыймов.

Шушы арада гына булган бер хәлне дә сөйләп күрсәтте ул. Казандагы сак оешмаларының берсендә техник куркынычсызлык өчен җавап бирүче, зур кәнәфидә утыручы берәү мошенникларга өч сәгать эчендә 7 миллион сум акча күчергән. Аны булмаган акчасын урларга мөмкиннәр, дип төп башына утырткканнар. Имеш, читтән торып зур суммада кредит рәсмиләштереп маташалар, моны булдырмас өчен, ашыгыч рәвештә банктан шул кадәр үк акча алып, аны «куркынычсыз счет»ка салып куярга кирәк.

– Зур суммада акча югалтучылар бихисап. Бер генә көнне мисал итеп китерәм: 26 июльдә хокук саклаучыларга мошенниклар корбанына әверелеп, 1 миллион сумнан күбрәк акчасын югалткан 13 кеше мөрәҗәгать итте, – ди Рәмис Газыймов.

Күз күрмәгән, колак ишетмәгән инвестиция, биржа фондларында баеп китәргә теләүчеләр дә күп. Мондый ялган тәркемнәр социаль челтәрләрдә бихисап, дип кисәтәләр очрашуда. Электрон акча янчыгындагы ялган керем белән башны бутыйлар да аннан соң аны чыгару өчен комиссия сорый башлыйлар.

Заманасына күрә, интернеттан яки бушлай игълан сайтларыннан товар сатып алырга теләүчеләрне дә рәхәтләнеп кәкре каенга терәтәләр. «Мондый мошенникларның очына чыгу җиңелрәк», – ди идарә җитәкчесе урынбасары. Алай да, төрле тәкъдимнәргә кызыгып, акча күчерә башлаганчы, интернеттагы мәгълүматны җентекләп өйрәнергә киңәш итте ул.

«Туганыгыз юл һәлакәтенә очрады», – дип, нигездә өлкән яшьтәгеләргә шалтыраталар икән. Пенсионерлар кырыгалдарларга 100 меңнән 1 миллион сумга кадәр акча күчерә.

Мошенниклыкның яңа төре – күптән түгел Казанда военкоматларга ут төртергә тырышу очраклары да нәкъ менә аларга бәйле.

– Алдакчылар бер тапкыр үз кармакларына эләгүчеләргә кабат шалтыратып, кушканны эшләсәгез, акчагызны кайтарабыз, дип алдаган, йә туганнарына янап, хәрби комиссариатларга ут төртергә кушкан. Шул рәвешле халыкны җинаять кылырга мәҗбүр итәләр, – дип сөйләде Рәмис Газыймов.

Урлау һәм мошенниклык очракларын фаш итү буенча Татарстан Идел буе федераль округында – беренче, ә ил күләмендә исә – дүртенче урында. Тик аңа карап кына эш кимеми.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

«ВИШНЯ ҮЗЕБЕЗНЕКЕ, ВКУСНАЯ...»

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ БАЗАР ХӘЛЛӘРЕН БЕЛЕШТЕ

Автор фотосы

Иртәнге сәгать 10.00. Базар гөрли. Шәһәр халкы ашыга-ашыга кышка әзерләнә. Җиләк-җимешләрдән – чия, карлыган, кура җиләге, яшелчәләрдән кыяр, помидор, ташкабак сатучыларның аеруча рәхәт көннәре. Бәяләре ничегрәк соң? Казанның «Колхоз базары»на барып, шуны белешеп кайттык.

«Матурым, вишня үзебезнеке, вкусная – алып җибәр әле». Базарга бераз керүгә, Югары Осланнан килгән Венера апа Нигъмәтуллинаның ягымлы тавышы ишетелә. Чиянең бер килосын 250 сумнан сата ул. «Быел уңыш әйбәт, Аллага шөкер. Үзебезнең уңыш! Хәзер сезоны бит – алучылар да шактый. Кем – компот, кем кайнатма ясап мәш килә», – ди Венера апа.

Чыннан да, чиләкләп-чиләкләп алалар чияне. Карлыган, алма, крыжовник сатучылар тирәсендә дә халык хәйран иде. «Элек авылда тора идем. Хәзер кызым янында. Гомер буе кара карлыганнан кайнатма ясадым. Шуннан башка чәй эчә алмыйм. Менә биш литр булса да алыйм дигән идем. Хәйран кыйммәт икән бәяләре», – дип аптырап тора иде Миңнегөл апа. Базарның эчендәрәк тагын бер очраштык без. Анда карлыганны кулайрак бәядән саталар булып чыкты.

Без җәй буе авыл кырларыннан, урманнардан җыйган файдалы үләннәр дә сату өстәләренә килеп «кунаклаган». Аня исемле әбекәй оныгы Тимур белән үләннәрне Кама Тамагы районының Тәмте авылы тирәсеннән җыя икән. «Чип-чиста урыннар. Курыкмыйча ал, кызым. Зәңгәр мәтрүшкәнең бәйләме – 150, сары мәтрүшкә һәм ромашка 50шәр сумнан», – дип кыстады ул.

Яңгырдан соң чыккан гөмбәләр кебек, базарда гөмбә сатучылар да еш очрап торды. Биектау районының Дөбьяз авылыннан гөмбә белән тулы зур-зур чиләкләрен күтәреп килгән Оркыя апа, быел уңыш әллә ни юк, ди. «Без, кызым, гөмбәчеләр түгел инде. Шулай да, аз-маз җыйгалыйбыз. Ара-тирә монда да алып килеп сатабыз. Безнең якларда майлы гөмбә генә. Әтәч гөмбәсе ишеләрне Маридан алып килеп саталар», – ди ул.

Шунысы кызык: монда кайбер гөмбәнең чистартылмаганы да, чистартылганы да сатыла. Икенчесе ике мәртәбә кыйммәтрәк. Кайсы күбрәк сатыла дип уйлыйсыз? Юк шул, очсызрагы түгел икән. Тагын бер нәрсәгә игътибар иттек: кыяр тозлау өчен кирәк булган сарымсак, кура җиләге яфрагы, укроп ише вак-төякне бер банкага җитәрлек итеп ясап саталар иде. «Бер бәйләмен 30 сумга сатабыз. Ясап өлгереп булмый – алып бетерәләр. Кеше ялкауландымы шунда... Дөресен генә әйткәндә, боларны аерым-аерым алсаң, очсызгарак чыгар иде», – диде шундый бәйләмнәр ясап торучы Ольга ханым.

Кышка әзерләнәм дип, тирләп-пешеп, банка капларга теләмәүчеләр базарның эчке өлешенә рәхим итә ала. Анда әзерләре сатыла. Хезмәтенә күрә бәясе, дигәндәй, әзернең бәясе дә бар инде. Әйтик, маринадланган сарымсакның бер литрлы банкасын – 500, суганны – 250, майлы гөмбәне – 1000, баллы гөмбәне 900 сумга саталар. Ташкабак һәм чөгендер икрасының ярты литрлы банкасы 250шәр сумнан.

Базарны бер-ике кат урап, кайтырга чыкканда, зур сумкалар күтәргән тагын бер әби очрады. «Базарга килүем генә әле. Кайбер сатучылар әшләрен бетереп кайтып китсә, мин икенче «смена»да эшлим. Монда бит кеше көнозын өзелми. Авылдан эремчек, кура җиләге, йомырка алып киләм», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«КОЛХОЗ БАЗАРЫ»НДАГЫ БӘЯЛӘР, сумнарда:

Җиләк-җимеш (бер килосы)	
Чия	180–250
Бакча җиләге (виктория)	300
Кук җиләк	450
Кура җиләге	300–500
Алма	30–80
Крыжовник	250
Кызыл карлыган	200
Кара карлыган	400
Кавын	70
Карбыз	50
Груша	50–200
Сырганак	200
Урман чикләвеге	500
Яшелчә (бер килосы)	
Бәрәңге	45–60
Помидор	80–140
Кыяр	50
Ташкабак	60
Кишер	70
Татлы борыч	130
Ачы борыч (бер данәсе)	50
Чөгендер	50
Борчак	300
Кукуруз (бер данәсе)	50
Кәбестә	50
Суган	60
Редис	150
Баклажан	100
Сөт ризыклары, йомырка	
Сөт (бер литры)	80
Эремчек	300
Каймак	600
Йомырканың бер дистәсе	100–120
Гөмбә (бер килосы)	
Әтәч гөмбәсе	350
Ак гөреҗдә	300
Каен гөмбәсе	500
Майлы гөмбә	250

Татарстан районнарында шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу бәяләре

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, халыктан җыела торган сөткә республика буенча уртача 18,10 сум түлиләр, авыл хуҗалыгы оешмаларына – 25,59 сум.

Арча	19,06 сум
Апас	16 сум
Аксубай	18,40 сум
Балтач	21,50 сум
Буа	19–20 сум
Кукмара	19–21 сум
Мамадыш	20 сум
Мөслим	16–17 сум
Саба	19 сум
Теләче	20,55 сум
Чүпрәле	16 сум

Язучы сүзе

Эзләү

Тукта әле, энем, алай димә әле. «Сыерың кайтмый калдымы әллә?» – дип көләргә ашыкма әле син. Үзең дә белеп торасың бит инде, мал тотарлык яшьтән узганмын. Яшьләр дә сыер асрарга бик атлыгып тормый хәзер. Шулай булгач, мин нишләп ул кадәр казганырга тиеш. Сыер эзләп чыкмадым, энем. Нәрсәдер эзлим эзләвен, тик нәрсә икәнен үзем генә аңлап җитә алмыйм. Хәтер юк бит хәзер. Баш та бик эшләми бугай. Башың эшләмәсә, аякларга көч төшә бит ул. Менә мин дә йөрим әле шулай...

Кара әле, син чишмә суы өчен акча бирмәдең бугай бит әле? Чокырын тазартып, ниндидер яңа аппарат алып куймакчылар икән. Шуның өчен өй башыннан акча җыялар. Кыйммәт дип, кирәкнең кыйммәте юк инде, энем. Менә мондый эссе җәйләрдә сусыз торып булмый бит. Эчәм-юынам дисәң дә, бакчага сибәм дисәң дә, шул кирәк. Яңгыры да юк бит, ичмасам. Шулай булгач, нихәл итәсең инде?! Мин бирдем. Мунчаны нытырга дип җыйган акчаның яртысын тоттырып җибәрдем. Су булмаса, мунчаның ни хаҗәте кала инде?!

Һаман нытымадыңмыни дип... Теге вакытта бит юлларны карау өчен акча җыйдылар капка башыннан. Язын-көзен урамга аяк басарлык та түгел иде, үзең беләсең ич, менә ком салып, тигезләп куйгач, Аллага шөкер булып калды. Шәһәр урамыннан йөргән кебек күкрәк киереп йөрибез. Мунча нытытам дип, андый эштән читтә калып буламыни?! Мунчаны атнасына бер-ике генә ягып керәсең, ә урамга көн дә чыгабыз. Гомер булса, Ходай бирсә, җыелыр әле, дидем.

«Җыелдымы соң?» – дип... Җыелды, Аллага шөкер. Кирәк-яраклар алырга район үзәгенә барырга да уйлаган идем, күперне карарга кирәк булып чыкты. Мин бит кибеткә гел шул күпер аша чыгып йөрим. Көн саен. Бәй, икмәге-сөте кирәк бит инде. Булса, башкасы да артмый. Рас шулай икән, бирми калып булмый. Бирдем. «Ярый әле төзелеш кирәк-яраклары алып, акчамны туздырмаганмын», – дип сөенә-сөенә бирдем. Үзебезнең авыл бит инде, үзебез карамасак, кем карасын?!

Аннан соң мәчеткә әйберләр алырга дип акча җыйдылар. Зиратка. Барысы да кирәк бит инде. Күрәге генә дә фәлән сум тора бит аның. Печәнен чабарга, агачларын кисеп торырга кирәк. Бер аягың җирдә, икенчесе гүрдә чагында чүтлашып торып буламыни?! Теге чалгылы адәм килеп якаңнан алса, мунчаң да, чуртың да кирәкми. Шунда китәсен, үзең акча бирергә кызганган зиратка. Алай булмаган хәлдә дә үз өлешеңне кертергә кирәк. Ата-аналарыбыз, әби-бабаларыбыз шунда ята ич. Барыбыз да шунда кайтачакбыз. Әнә Капкорсак Зарифның улы Комак Гарифне дә шунда кайтарып күмделәр. Шәһәрдә әллә ничә катлы йортлары, дачалары, тагын әллә нәрсәләре бар икән, бик бай икән, дип сөйлиләр иде. Булса булгандыр, тик мөлкәтенең сукыр бер тиене дә әйләнеп кайтмады. Шулай булгач, мунча нытасы бар, дип саранланып ятып буламыни?!

Аннан соң, энем, мәктәп түбәсеннән дә су үтә иде бит. Аңа да җыйдык инде. Бәй, мәктәп бит ул! Ул бит – безнең балаларны аң-белемгә өйрәтә торган урын. «Яңадан төзибез», – дисәләр дә, бергәләшеп җыелыр идек. Гыйлем-тәрбия бирә торган нәрсәгә берни дә җәлке түгел. Тик анысы бераз кызганычрак булды инде. Без, акча җыеп, мәктәпнең түбәсен яптык, районнан зур түрәләр килеп, мәктәпне яптылар. Укытучыларның бер өлеше эшкә чыкмады, бер өлеше фермага урнашты. Кайсы үгез симертә, кайсы сыер сава. Шунысы бераз юаныч: тиздән халык профессиональ педагоглар тәрбияләгән сыер малының итен ашаячак. Хакы артыр инде, кәнишне.

Тукта әле, энем, бәйләнмә әле син. Ничә ел буена бер мунчаңны карый алмыйсың, дип... Ел да менә шундыйрак мәшәкатьләр чыгып тора ич. Әнә электр баганалары да кыйшая башлаган әле. Мунча дип торып булмас. Ярый, сасып йөрмим бит. Уртак хәстәр хакына аз гына җайсызлыкка түзәргә дә була. Тукта инде, тукта. Бәйләнәсең дә торасың син. Бер җылы сүз әйтсәң, булмыйммыни?! Нәрсә эзли идем соң әле мин? Белмим инде, энем. Үзенең ни эзләгәнен, ни тапканын, нәрсә югалтканын бер адәм дә белми бугай хәзер.

Акча түгел, энем. Акча җитә, бернәрсә дә сатып алмасаң, азрак артып та кала әле. Эзләгән нәрсә акча түгел...

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

«Утырып сәдис»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу сүзләр телебезгә кайчан, ничек килеп кергәндер, бернинди аңлатма да таба алмассыз. Тел гыйлемендәге бернинди кагыйдәләргә дә сыймый ул, әмма без аны кемгә булса да хөрмәт йөзеннән кулланабыз. Дусларга, кунакларга: «О-о, утырып сәдис», – дип әйтү якын итеп дәшү кебек кабул ителә һәм моңа татары да, русы да үпкәләми. Әмма тормышта кайчак «утырып сәдис» димичә дә арт шәрифләребезгә «лып» итеп утырырдай хәлләр очрый.

Беркөнне университетта бергә укыган, университетның татар хорында бергә җырлап йөргән Роза шалтыратты. Мин аны искә төшерә алмый азапландым. Телефон аша фотосурәтен җибәргәч кенә искә төште. Роза биология факультетында укыды, әмма күңелендә милли хисләрен сүрелдермичә гомер итә. Үзе әйтмешли, «Ватаным Татарстан»ның фанатигы да икән. «Аптырагач, сиңа шалтыратырга булдым, без ни өчен үз телебезне үзебез мыскыл итәбез?» – диде дә Казан Кремле диварындагы язулардагы хаталар турында сөйләп китте. Бер-ике фоторәсем дә җибәрде. Дөресен әйткәндә, минем Кремль якларына күптән барганым, андагы язуларны укып йөргәнем юк. Шуңа күрә Роза җибәргән рәсемнәрне күргәч, «лып» итеп артыма утырганымны сизми дә калдым. Шөкер, «Кремль» урынына үзебезчә матур итеп «Кирмән» дигән сүз куллана башладык. Дөрес, белгечләр әйтүенчә, Кремль үзе дә – төрки сүз, «кирмән»нән алынган. Бу турыда «по политическим соображениям» дигәндәй, бәхәс бара үзе. Ярый, сүзебез башка бүген. Иң кызыгы: «Казан йөрәге»ндәге таш диварларда «кирмән» сүзе нигәдер «Киирмән» дип ике «и» белән язылган. Моны дөрес язу өчен шулхәтле грамота кирәк булды микәнни? Сабакташым җибәргән тагын бер фоторәсем шулай ук диварлардагы язулар өчен җавап бирүчеләрнең ни дәрәҗәдә укымышлы булуларын күрсәтә иде: шартлар (условия) дигән сүзне «шарталар» дип язганнар. Сабакташым Роза: «Риман, бу бит каядыр Казан читендәге стеналардагы язу түгел, башкалабыз үзәгендә, Кирмәндә!» – дип өзгәләнә. Һәм инде бу язулар беренче ел гына «күз явы»н алып тормый икән. Безгә елына миллионлаган турист килә. Алар Казан Кирмәненә керми калмыйлар. Диварлардагы язуларга да күз салмый калмыйлардыр. Шул 4 миллионга якын турист арасында татарча укый белә торган фәлән мең кеше булмый калмас һәм алар, хаталы язуларны күргәч, нинди уйлар белән кайтып китә икән?

Ярый, кунаклар ул язуларга игътибар итмәс тә дип уйлыйк. Әмма «лып» итеп «утырып сәдис»лек тагын бер мәсьәлә бар әле. Без элмә такталардагы, топографик тамгалардагы, торак йортлардагы төрле язуларда хаталар эзләп табу буенча бәйге игълан иттек. Җиңүчеләрне билгеләп, аларга кыйммәтле бүләкләр тапшырабыз. Бу бәйге – тел бозу мәсьәләләренә киң җәмәгатьчелек игътибарын тарту өчен бик әһәмиятле чара. Әмма кемне җиңәбез, кемгә каршы көрәшәбез? Без һәрвакыттагыча нәтиҗә белән көрәшәбез. Башта төрле кыенлыклар, төрле проблемалар тудырабыз да аннан геройларча шуларны хәл итәргә тырышабыз, тискәре күренешләргә каршы аяусыз көрәш игълан итәбез. Бу – безнең яшәү рәвеше. Ә нигә яман нәтиҗәләргә китергән сәбәпләргә каршы көрәшмибез? Йомшак кына әйткәндә, ул сәбәпләргә күз йомабыз. Күк күкрәми мужик чукынмый шул. А как жаль…

Әлеге элмә такталардагы хаталар өчен дә кемдер җаваплы бит инде. Үз эшләренә җавапсыз караучыларны ни өчен җавапка тартмаска ди, мәсәлән?! Дәүләт теле статусы алган телебезне санга сукмау, аны бозу нәрсә дип бәяләнергә тиеш икән? Җинаять дипме, эшкә салкын карау дипме, ваемсызлык дипме? Әллә «белми һәм белә торып» кылынган гөнаһмы бу? Тел саклау – иманыңны саклау. Татар телендәге элмә такталарда хаталарны табу бәйгесе турында мәгълүматлардан күренгәнчә, андый хаталар меңәрләп санарлык икән. Шуны уйлап куйдым: әгәр рус телендәге элмә такталарда шулхәтле хата булса, рус кардәшем «утырып сәдис» димичә дә «лып» итеп арт шәрифләренә утырыр иде. Ә без нәрсә? Без бернәрсә дә, беркем дә түгел кебек тоелып китә. Хакимият баскычларында үз телен камил белгән бер генә татар да калмады микәнни?

УТ САЛУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Соңгы көннәрдә автор телеграм-каналларны ачарга өлгерми, хәрби комиссариатларга ут төртү турындагы хәбәрләргә тап була. Ут салу очраклары саны көннән-көн үсә һәм шик юк: илдә чып-чын эпидемиягә әверелеп бара. Ябь-яшь кызлардан алып яше 85кә җиткән картларга кадәр, билгесез кешеләрнең боерыгына буйсынып, яндыргыч шешә ясый һәм җинаять юлына баса.

Күбесе нәтиҗәсез тәмамлана, әмма зомби хәленә китерелгән җинаятьчеләр гамәлләре өчен барыбер җавап бирәчәк. Махсус хәрби операция башлангач, Россиядә законнар катыланды, 15–20 еллык срокны «эшләп алу» хәзер берни түгел. Ут салу шаукымы белән Украинаның Мәгълүмати-психологик операцияләр үзәге идарә итә, диләр. Сак булырга, миләрне яулап алып, зомбига әйләндерүчеләргә бирешмәскә өндәгән язмалар телеграм-каналларда да, матбугат битләрендә дә күренә башлады инде. Әмма телефон мошенниклары тарафыннан халыкның алдануы инде күп еллардан бирле барганны искә алганда, ут салуга һәм шартлатуга этәрә торган телефон терроррыннан җиңел генә котылып булмас кебек.

Әйдәгез, кешеләрне җинаятькә этәрә торган мотивларның берничәсен карап үтик. Мошенниклар синең исемгә кредит рәсмиләштерә, алар хәрби комиссариатта утыра, котылу өчен, кичекмәстән барып, ут төртергә кирәк дигән ялганга ышана күпләр. Икенче бер катлау башта, алданып, мошенниклар хисабына миллионлаган сум акча күчерә дә шуларны кире кайтарып алу өчен ут төртергә дигән шартны үтәргә ашыга. Җинаятьне видеога төшереп, мошенникларга җибәргәч, акчасы кире кайта, дип уйлый. Хәрби комиссариатта хыянәтчеләр утыра, яшерен мәгълүматны украиннарга тапшыралар, шуларны юк итәргә дигән миф шәйләнә тагын. Монысына ышанучылар да җитәрлек. Элемтәнең теге башында «ФСБ офицерлары» утыра, рәсми затларга, бигрәк тә яшерен хезмәт вәкилләренә берсүзсез ышану безнең канга сеңдерелгән. Курку катыш ышану дип өстәргә кирәктер, мөгаен.

Телеграм-каналларда төрле аналитиклар вазгыятькә үз карашын белдерә, төрле фикерләр әйтелә. Кайберәүләр белем бирү системасының начар булуыннан күрә әлеге галәмәтне. Чынлап та, бигрәк наив, бигрәк беркатлы алдана бит кешеләр. Баш миен аз гына эшкә җиксәң дә, йогынтыдан бик җиңел чыгып булырга тиеш кебек күренә югыйсә. Мәсьәлә шулай җиңел генә булса икән! Телефон мошенниклары кармагына бик яхшы интеллектуаллар һәм белгечләрнең дә еш кабуын искә алганда, мәгариф системасының аксавы белән генә аңлатырлык күренешләр түгел бу. Безгә каршы бер явыз система эш итә. Корбаннарны бик белеп сайлый, бик нечкә алымнар белән аларга тәэсир итә. Гипнозлый. Җәмгыять тоталь рәвештә соңгы елларда шундый гипнозга бирелүчән итеп тәрбияләнде һәм тәрбияләнә.

Шундый тәрбия бер Россиядә генә түгел, глобаль рәвештә бөтен дөньяда бара. Кешеләрдә ялганга иммунитет максатчан рәвештә бетерелә һәм рәсми боерыкларга берсүзсез ышанучанлык сеңдерелә. Экстремаль шартларда, чынлап та, җитәкчелеккә берсүзсез буйсынмый булмый, чөнки катлаулы вазгыятьтән ныклы дисциплина белән генә чыгып була. Һәм без планетакүләм беренче экстремаль шарт белән очрашабыз: ковид пандемиясе мәйданга чыга. Монда бәхәсләшеп торып булмый инде: бикләнергә кушалар икән, бикләнәсең, вакцина ясатырга кушсалар, ясатасың. «Вакциналаштыру турында моңарчы яшәп килгән медицина протоколлары ни өчен юкка чыгарылды?» дигән сорауны биреп тора алмыйсың. Махсус хәрби операция һәм мобилизация белән дә шул ук хәл. Тәнкыйди фикерләү катгый тыела. Чакырганда хәрби комиссариатка килмәүчеләргә законнар ничек катыланды! Телефон аша гипнозлаганда менә шулар алгоритм итеп кулланыла да инде. Сиңа рәсми рәвештә ФСБ полковнигы шалтырата. Ышанмас идең, аның кулында синең турында тулы мәгълүмат бар. Кайда яшәвеңне белә, телефоның һәм паспорт мәгълүматлары да аның өчен сер булмаска мөмкин. Син барып ут салырга тиешле объектның да төгәл адресы бар кулында. Тәнкыйди фикерли башласаң, син аны җиңел генә чиста суга чыгарыр идең, әмма, гафу итегез, ул рәвешле фикерләү тыела, безне алай өйрәтмәделәр. Монда бик күп шәхси мәгълүматның сатылуы, иркенгә чыгарылуы проблемасы да бар әле. Рәсми оешмалар аны сакламыйлар. Сер түгел, кайвакыт банк хезмәткәрләре дә синең хактагы мәгълүматны мошенникларга сата.

Бу алгоритмга курку дигән нәрсә килеп кушыла әле тагын. Яшерен хезмәтләрдән курку. Моннан берничә ел элек миңа бер ришвәтче турында зар килеп керде. Зарланучылар – интеллектуаллар, ягъни төшеп калган кешеләр түгел. Мин аларга каракны фаш итәргә, ришвәт түләмәскә кушам. «Юк, мөмкин түгел, – диләр. – Ире – ФСБ офицеры аның». ФСБ офицеры булу чикләнмәгән хакимлек бирми, аңа да авызлык табып була дигән дәлилне колакларына да элмиләр. Соңыннан фаш ителде ул ришвәтче, йөрәк өянәге белән хастаханә палатасында сак астында ятты, ире дә яшерен хезмәтләр вәкиле түгел икән, анысы да ачыкланды. Әмма факт көч структурасының югары катлавында урнашучылардан куркуның җәмгыятьтә ничек көчле булуын дәлилли. Украинада Мәгълүмати-психологик операцияләр үзәге дигән оешма чынлап та булган очракта, анда бик яхшы профессионаллар утыра торгандыр. Яшерен хезмәтләр вәкиленнән курку ярдәмендә кеше ихтыярын ничек богаулап куеп булуын яхшы беләләрдер.

Икенче курку – мал югалтудан курку да бар әле. Соңгы унбиш елда бездә кредитоманнар армиясе үстерелде. Кредит коллыгына бер төштеңме, ул чиргә әйләнә, котылу авыр. Аз гына кредит биреп, аны миллионлаган сумлык бурычка үстергән микрофинанс оешмалары күпме кешенең башына җитте икән соңгы дистә елда? Моның статистикасы бармы? Аннан соң абруйлы дип саналган банклар да, килешүнең иң мөһим өлешен вак хәрефләр белән язып, күпме кешене кармакка эләктерде. Түләгән өстенә түләттеләр. Шуңа күрә синең исемгә кемнәрдер зур суммада кредит рәсмиләштерә дигән хәбәр акылны томалый һәм күңелдә вәсвәсә давылы кузгалта. Бу юлларның авторы беркайчан да бер тиен дә кредит алмады, әмма телефонымдагы банк кушымтасын беренче тапкыр ачканда, «Кредиты» дигән сүз астындагы «Предварительно одобрен» дигән сүз күңелгә бик зур шом салган иде. Шунда ук банкка шалтыраттым, үземнең кредитка гариза язмавымны әйтеп, аңлату таләп иттем. Менә шундый хәлләр инде. Банкирлар туктаусыз «салкын» шалтыратулар белән дә халыкның башын бик бутый. Соңыннан мошенник шалтыратамы, банк хезмәткәреме икәнен ачыклый алмас хәлгә килә кеше.

Вазгыятьнең нечкә якларын бик яхшы белгән психологлар мәгълүмат кырында зур сугыш башлап җибәрде. Мантыйк буенча фикерләгәндә, алар һөҗүменә дучар булучылар җиңел генә бирешмәскә тиешләр кебек тоела. Әйтик, ут төртеп җәфаланганчы, хәрби комиссариатка барып, хәлне ачыклау яисә полициягә хәбәр салу җиңелрәк. Читтән караганда, иң оптималь юл шул ич инде. Әмма… хакимият вәкилләренә берсүзсез буйсыну белән янәшә аларга ышанмау дигәне дә яши бит әле күңелләрдә. Үткән ел өлешчә мобилизацияне ничек башлаганнарын хәтерлибез. Хәтта Путин «мәгънәсезлек тулып ята» дип бәя бирде күзге хәлләргә. Әйтик, безнең районның хәрби комиссары мобилизация барышында кулга алынды. Менә шундый комиссарга барып, сереңне ач инде син! Шулай булгач, элемтәнең теге ягындагы «ФСБ офицеры»на ышанмый да булмый, дип уйлый башлый кешеләр. Аның кушуын үтәү иң дөрес һәм җиңел юл булып тоела. Башта ут күңелләргә салына, аннан соң гына военкомат тәрәзәсенә «Молотов коктейле» булып оча.

Кайдадыр сиңа каршы сугыш игълан иткән психоаналитик үзәк бар икән, аңа каршы көрәшергә сәләтле икенче үзәк тә булырга тиештер инде, мөгаен. Кешеләргә акны карадан аерырлык тәнкыйди фикерләү мөмкинлеген кире кайтармасак, зомбиларның зур армиясенә каршы сугышырга туры килергә мөмкин. Сугыш вакытында ялган рөхсәт ителә, билгеле. Рөхсәт ителә. Әмма үз халкыңны түгел, дошманны гына алдарга ярый. Киресенчә гамәл кылынса, без контрольгә алып бетереп булмаслык хәлләргә кереп батачакбыз. «Ут салу» операциясе шуны искәртә кебек.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Автор фотосы

МАЯ КҮКТӘН ТӨШМИ

Тиздән кесәдәге акчаны арттыруның яңа ысулы гамәлгә керәчәк. 2024 елдан илдә озак вакытка исәпләнгән акча саклау программасы эшли башлаячак. Анда теләге булган һәркем катнаша ала. Хәтта башка кеше, мәсәлән, бала өчен дә финанс «мендәр»е тупларга мөмкин. Шул рәвешле халыкны азмы-күпме акча җыярга өйрәтмәкчеләр, ди белгечләр. Дәүләт тә ярдәм итәргә әзер. Яңа программа ярдәмендә күпме акча туплап була? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауга җавап эзләде.

Россия Президенты Владимир Путин озак вакытка исәпләнгән акча саклау программасы турындагы канунны имзалады. Яңалык киләсе елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керәчәк. Илнең Финанс министрлыгы һәм Россия Үзәк банкы тәкъдим иткән әлеге финанс инструменты үзенең һәм балаларының киләчәге турында кайгыртучыларга отышлы булачак, ди белгечләр. Моның өчен әллә ни күп тә кирәкми кебек. Дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды белән килешү төзисең дә шунда даими рәвештә акча күчереп барасың. Озак вакытка дип тапшырган акчаны «Кертемнәрне иминиятләштерү буенча агентлык» дәүләт корпорациясе иминиятләштерәчәк.

Кемнәр катнаша ала?

Программада 18 яшьтән башлап теләге булган һәркем катнаша ала. Дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды белән килешү төзегәндә, беренчел кертем күләмен, аның вакытын һәм суммасын үзең билгелисең. Тик шунысы бар: килешү ким дигәндә 15 елга төзелә. Ягъни түләүләр әнә шул вакыттан соң гына: хатын-кызларга – 55, ир-атларга 60 яшь тулгач килә башлаячак. Берьюлы берничә фонд белән килешү төзергә дә мөмкин. 2,8 миллион сумга кадәр җыелган акча иминиятләштереләчәк. Чагыштыру өчен: банк кертемнәре өчен әлеге күрсәткеч 1,4 миллион сум тәшкил итә.

Акча ничек туплана?

Мая, иң беренче чиратта, фондка даими кертемнәрдән җыелачак. Шулай ук, программага пенсиянең 2014 елдан бирле «катырылган» тупланма өлешен дә күчерергә рөхсәт итәчәкләр. Соңгысына ачыклык кертик. Билгеле булганча, хезмәт хакының 22 проценты күләмендә акча Пенсия фондына күчерелә. 2002 елда пенсия системасына яңалык керде һәм Пенсия фондына күчерелгән акчаның бер өлеше (16 проценты) – иминият пенсиясенә, ә калганы (6 процент) тупланма пенсиягә китә башлады. Тик бу эш 2014 елда туктатылды. Пенсиянең тупланма өлеше «катырылган» дигән сүзләр әнә шуннан чыккан да инде. Дөреслектә, бу акча юкка да чыкмаган, катырылмаган да. 2014 елда илдә пенсиянең тупланма өлешенә мораторий кертелде. Гади тел белән әйткәндә, хезмәткәрләр өчен күчерелә торган акча алдагы кебек икегә бүленми. 22 процентның барысы да пенсиянең тупланма өлешенә китә. Илбашы Владимир Путин тупланма өлешне «катыру»ны 2025 елга кадәр озайтты.

– Мораторий моңарчы җыелган акчаны төрле фондларга күчерү мөмкинлегенә берничек тә комачау итми. Тупланма өлештә җыелган акчаны нишләтергә икәнен һәркем үзе хәл итә. Аны Пенсия фондында калдырырга яки дәүләтнеке булмаган пенсия бүлекләренә күчерергә ярый. Пенсия акчасыннан аермалы буларак, тупланма өлеш дәүләт тарафыннан индексацияләнми. Аннан керем генә алырга мөмкин. Суммасына карап, тупланма өлеш берьюлы (әгәр җыелган акча иминият пенсиясенең 5 процентыннан да кимрәк икән, ул берьюлы бирелә. – **Ред.**) яки өлешләп түләнә. Тупланма өлеш кеше үлгәннән соң да юкка чыкмый. Аны варисларга түлиләр, – дип аңлаттылар Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлегенең матбугат хезмәтендә.

Үзәк банк мәгълүматларына караганда, илдә 70 миллионнан артык кешедә пенсиянең тупланма өлеше бар.

Күпме өстиләр?

Озак вакытка акча саклый башлауның беренче өч елында федераль бюджеттан ярдәм күрсәтәчәкләр. Әлеге чорны Хөкүмәт карары нигезендә озайту мөмкинлеге дә каралган.

Дәүләттән ярдәм күләме түләнгән акчадан һәм узган елгы уртача керем күрсәткеченнән чыгып билгеләнәчәк. Кесә ягы такыррак булган саен, ярдәм дә зуррак. Әмма 36 мең сумнан да күбрәккә өмет итмәгез.

✓Әгәр уртача керем 80 мең сумга кадәр булса, түләнгән һәр сумга 1 сум өстәп бирәчәкләр. Дәүләттән 36 мең сум күләмендә акчалата ярдәм алу өчен шулкадәр үк акча салырга туры киләчәк.

✓Әгәр уртача керем 80 – 150 мең сум тәшкил итсә, түләнгән һәр 2 сумга 1 сум өстәп түләячәкләр. Дәүләттән 36 мең сум акча алу өчен, хисап счетына 72 мең сум акча күчерәсе була.

✓Әгәр уртача керем 150 мең сумнан да артса, түләнгән һәр 4 сумга 1 сум өстәп түләячәкләр. Бу очракта күпме түләргә кирәк икәнен алар үзләре саный.

Моннан тыш, инвестицияләрдән алган керемгә салым түлисе булмаячак. Программада катнашучыларга салым чигерүе дә каралган – 400 мең сумга кадәр акча күчерүчеләр 52 мең сумга кадәр акчаны кире кайтара алачак. Дәүләт ярдәме ай саен кимендә 2 мең сум акча түләп баручыларга күрсәтеләчәк.

Кире алып буламы?

Программада катнашу киләчәктә өстәмә түләү алу мөмкинлеген тәэмин итәчәк. Аны билгеле бер елга яки гомерлек итеп исәпләтергә мөмкин. Кеше түләү билгеләнгәнче үлеп китсә яки аны алып бетерергә өлгермәсә (гомерлек түләү сайлау очрагыннан кала) акча аның варисларына күчәчәк.

Озак вакытка дип салынган акчаны, тормыш шартлары катлауланса, вакытыннан алда да алырга мөмкин. Мәсәлән, якыннарың, яки үзең каты авырып китеп, кыйммәтле дәвалану таләп ителсә, гаилә туендыручысыз калса, җыелган сумманы ничек бар шулай кайтаралар. Ә менә «башка түлисем килми» дип кенә программадан чыгып китәргә теләүчеләр, дәүләт өстәп түләгән акчаны да, пенсиянең тупланма өлешен дә күрә алмаячак. Салым чигерүе алган булсагыз, аны да кире кайтарырга туры киләчәк әле.

Дәүләткә моннан ни файда?

Россия – картаеп баручы ил, ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

– Билгеле ки, бүгенге эшчеләрнең кертеме хәзерге вакытта лаеклы ялда булучыларга пенсия түләүгә тотыла. Соңгы мәгълүматларга караганда, илдә яшәүчеләрнең 30 проценттан артыгы эшләү яшеннән узган. Бу сан артканнан-арта. Ягъни пенсия казанына акча өстәп торучылар кими. Шуңа күрә 2019 елдан илдә пенсия яшен арттыра башладылар да инде. Бүген илдә 40 миллионнан артык пенсионер исәпләнә. Заманасына күрә, илнең башка төр чыгымнары да артты. Шуңа күрә дәүләткә озак вакытка исәпләнгән акча кирәк, – ди белгеч. – Гади халыкның исә моның ише банк кертемнәре белән авызы күп тапкыр пеште инде. Шуңа күрә җиде кат уйлап, бер кат кисәчәкләр. Яңа программаның күзгә ташланып торучы кимчелеге – инфляция дәрәҗәсе исәпкә алынмаган. Унбиш елдан нәрсә буласын беребез дә әйтә алмый.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«БЕЛЕП ҖЫЯРГА КИРӘК»

Яңалык турында Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис ХӨСӘЕНОВ белән сөйләштек.

– Саклык программасы халык арасында кызыксыну уятачакмы?

– Дөресен генә әйткәндә, бу – дәүләт тарафыннан 2000 нче елларда башланган реформаның дәвамы. Сүз 2014 елга кадәр гамәлдә булган пенсиянең тупланма өлеше турында бара. Билгеле булганча, ул күбебездә бар. Канун нигезендә, алга таба дәүләтнеке булмаган Пенсия фонды белән килешү төзүчеләр әнә шул акчаны да файдалана алачак. Дәүләт исә кертемнәрне финанслауда катнашачак. Моңа өстәп, фонд эшкә җиккән акчадан керем алу мөмкинлеге дә бар. Бу эшне Үзәк банк контрольдә тотачак. Шуңа күрә халык акчасына шикле активлар сатып алырлар дип уйламыйм. Инфляция бүгенге кебек 10–15 процентка җиткән шартларда акчасын үзе теләп озак вакытка салып куярга теләүчеләр күп булыр дип уйламыйм. Тагын шунысы да бар: бездә киләчәккә мая тупларлык, аннан бигрәк, булачак пенсиясе турында кайгыртырлык кешеләр күп түгел. Хөкүмәт күзлегеннән караганда, бу – бик мөһим, әлбәттә. Көнбатыш илләренә күз салсак, аларның икътисадының тотрыклылыгы нәкъ менә пенсия, инвестиция фондларында тупланган акчаның күләменә бәйле. Мондый оешмаларда озак вакытка исәпләнгән инструментларга салырлык акча күбрәк булган саен, дәүләткә дә яхшырак.

– Без, гомумән, акча туплый беләбезме?

– Юк. Сәбәбе бик гади: финанс буенча грамоталылык җитми. Халыкның банктагы исәп-хисап счетларында саклаучы кертемнәренең уртача күләме 270 мең сум тәшкил итә. Күпме бу, азмы? Аз, әлбәттә. Дүрт кешелек гаиләгә бу акча, ул-бу була калса, өч-дүрт айга гына җитәчәк. Ә һәр гаиләнең кимендә ярты елга җитәрлек финанс «мендәр»е булырга тиеш. Айлык чыгымнарыгызны исәпләгез дә, шуны алтыга тапкырлагыз. Әлеге сумма гаиләнең финанс «мендәр»е була да инде.

– Бүген акчаны кайда һәм ничек сакларга?

– Инвестицияләр, кыйммәтле кәгазьләр белән эшләү тәҗрибәгез юк икән, зур табыш вәгъдә итсәләр дә, шикле активларга кызыкмагыз. Белмәгән җиргә кысылмавың хәерлерәк. Чөнки отам дип оттыруың да бар. Бу милек базары белән кызыксынучыларга да кагыла. Иң элек бу өлкәдәге вазгыятьне өйрәнегез. Әгәр маягыз артык зур түгел икән, аны банкта сумнарда саклавың хәерлерәк. Зур сумманы Россия валютасында тотарга теләмисез икән, евро яки доллар сатып алырга мөмкин. Шунысын да искәртик: чит ил валютасын банкта түгел, ә акчалата кулда сакларга кирәк. Ә иң мөһиме, акчаны булсын дип кенә түгел, ә нәрсә өчен икәнен белеп җыярга кирәк.

Сан

Дәүләтнеке булмаган Пенсия фондлары турында мәгълүмат Үзәк банкның рәсми сайтына урнаштырылган. Биредә ышанычлы оешмаларның исемлеге дә бар. 1 августка алынган саннарга караганда, рәсми исемлектә барлыгы дәүләтнеке булмаган 37 Пенсия фонды бар.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

НИГЕЗ САГЫНДА

Автор фотосы

Алабуга районының Көек авылында нибары бер кеше яши. Ләкин җәй җитүгә, авыл берничә гаиләне ниндидер күренмәс җепләр белән үзенә тартып кайтара. «Моннан икенче язга җитәрлек көч-куәт алып китәбез», – ди алар. Беткән авылга вакытлыча гына булса да җан өрүчеләрне нәрсә берләштерә соң?

Сакчы

Көек безне иң элек искиткеч матурлыгы белән таң калдырды. Нарат урманы арасына күмелеп утырган авылның йортлары күренгәнче, башта юлның як-ягында үскән мәһабәт агачларга хозурланып барасың. Бу юлдан узганда үзебезне әкияткә килеп эләккәндәй хис иттек. Аннан соң кыска гына урамлы кеп-кечкенә авылга килеп чыктык. Иң элек урамның икенче башында бала-чага тавышлары ишетелгән капкага сугылдык. Биредә оныклары белән Таһирә апа яши икән. Дөресрәге, җәйгә кайта. Авылда кунаклар тансык булганга, безнең килү малайлар өчен кызык булды. Яныбыздан бер минутка да китмәде шук егетләр. Мең сорау яудырып, сәпитләре белән озата йөрделәр.

Интернеттагы мәгълүматлар буенча, Көеккә 1680 елларда нигез салынган булырга тиеш. Халкы да төрле елларда төрлечә булган. Әйтик, 1938 елда – 243, 1970 елда 123 кеше яшәгән. Аннары кисәк кенә кими башлаган. 1979 елда биредә 70 кеше теркәлүен күрергә була. 2017 елда исә нибары 7 кеше калган. Без күреп аралашкан кешеләр әйтүенчә дә, кайчандыр авыл гөрләп торган. Кибете дә, клубы да, фермалары да, эше дә, мәктәбе дә булган. Хәзер инде кыска урамлы җыйнак кына бер авыл булып калган Көек. Ел әйләнәсе биредә нибары бер кеше яши.

Авыл башындагы беренче йортта ук торучы Рафис Сафинның үзен дә күреп сөйләштек. Көекнең төп кешесе әти-әнисе нигезендә яши. Әтисе мәрхүм булгач, ул шәһәрдән авылга бөтенләйгә күченеп кайткан.

– Мин Чаллыда яшәгәндә дә, авылга әтине караргa, тәрбияләргә гел кайтып йөрдем. Ул мәрхүм булгач, нигезне калдырасым килмәде, өч ел элек бөтенләйгә күченеп кайттым, – диде ул.

«Көзге караңгы, кышкы салкын көннәрдә үзегез генә яшәргә курыкмыйсызмы соң?» – дип кызыксындык яңа танышыбыздан. «Юк, курыкмыйм. Миңа кунаклар кайтып кына тора. Туганнар, балалар. Ә болай көннәрем йорт тирәсендәге вак-төяк мәшәкатьләр белән уза. Кар яуса, карын көрим. Мичкә ягып, йортны җылытам. Авыл советы рәисе Рәзимәгә рәхмәт, кышын минем йортыма кадәр юл ачтыра. Артыгы кирәкми дә, алайса чакырылмаган кунаклар килеп җәфалавы бар. Берничә тапкыр явыз ният белән сугылучылар булды, ләкин мин аларны авылның тегеочына җибәрмәдем. Авылны саклап, карап торучы бер кеше кирәк бит инде, – ди ул.

Аның сүзләренчә, авылда калуының мәгънәсе күпкә тирәндәрәк ята.

– Кайчандыр зур авыл иде дә Көек, хәзер бетте шул инде. Мин булганда бар әле ул, мин дә китсәм, бөтенләй бетәчәк. Шәһәргә китсәм дә, югалып калмаячакмын. Эшен дә, торыр урынын да табарга була. Тик мине монда нигез тота, аның туздырылуын теләмим. Бу йорт миннән бер яшькә генә кечерәк. Биш бала үстек монда. Беребез исән түгел инде. Калган туганнарым кайтып йөри. Шуңа күрә мин монда ялгыз түгел, – ди Рафис Сафин.

«Әти сүзе хак булды»

Көектә бер генә кеше кыш чыкса, яз, җәй җитүгә, авылга бераз булса да җан керә. Шәһәрнең тынчу һавасыннан туепмы, туган нигездә күңелләренә тынычлык эзләпме, авылдашлар кабат Көеккә җыйнала. Әйтерсең ниндидер күренмәс җепләр белән авыл аларны тартып кайтара. Без барганда да, өч-дүрт йортның капкалары ачык иде.

Бертуган Рәйсә һәм Рәйхана Шакировалар да ишегалларында кайнаша, чишмәгә суга барырга йөриләр иде.

– Без шушы йортта тугыз бала үстек. Абыебыз гына бик яшьли үлде. Әниебез аның кайгысын күтәрә алмады, шулай ук иртә китте. Әтиебез Миннәхмәт – Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше. Әнидән соң 25 ел ялгызы яшәде. Башта җәенкышын авылда торды. Аннан соң авыл тарала башлагач, кышны бездә чыга да җәйгә авылга кайта иде. Үз акылында, аңында булып, 93 яшендә безне калдырып китте. Аның бакыйлыкка күчкәненә дә тугыз ел булды инде. Әти-әни булмаса да, авылыбыз бетсә дә, туган нигез барыбер үзенә тартып тора. Җәй көне барыбыз да шушында җыелабыз. Элек авылыбыз зур, гөрләп тора иде. Көтүгә урам тутырып сыерлар куыла, халык атларга кадәр асрый иде, – дип искә ала Рәйсә апа.

Миннәхмәт бабайның икенче кызы Рәйхана апа кышын Чаллыда яши, ә җәйне тулысынча авылда уздыра икән.

– Туган нигезебезне ташламадык инде. Мин апрель ахырында кайтам да көз көне кире шәһәргә китәм. Ә калган туганнар атна саен кайтып йөриләр, бик нык булышалар. Бакчага бөтен яшелчәне утыртабыз. Җиләк-җимеш агачлары да бар. Урманыбыз да бик бай безнең. Быел корылык булгач, җиләк үсмәде. Ләкин узган ел искитмәле күп иде. Үземә, туганнарга әзерләп бетергәч, җиләк сатып, 10 мең сум акча да эшләдем хәтта, – диде ул.

Халык авыл таркалуның төп сәбәбе дип газ булмауны әйтте. Авылга газ кертелмәгән икән, йортларны мич ягып җылыталар.

– Авылның менә шулай япа-ялгыз калуы борчый да ул, тик без нишли алабыз соң? Бәлки халкы калган да булыр иде, газ булмады бит бездә. Газ булса, кыш көне дә кайтып-китеп йөрер идек, – диде Рәйсә апа. – Салкын көннәрдә җәен дә йортны мич ягып җылытабыз. Бездә үзәкләштерелгән су да юк. Һәркем үз хуҗалыгына кое казытты. Аннан соң авылларда яшьләргә эш калмады. Акрынлап ат, сарык, сыер фермалары, маллар бетте, авылның тамырына балта белән тагын бер кизәнү иде бу. КамАЗ төзелгәч, яшьләрнең барысы да диярлек шунда барып урнашты, тора-бара Чаллыга бөтенләйгә күченеп киттеләр. Авылның шулай акрынлап сүнә баруына әтиебезнең эче бик сыза иде. Маллар бетә бит, болай булгач, авылның да киләчәге булмас, дип әйтә иде. Сүзләре хак булып чыкты. Элек Көектә мәктәп тә булган, тик безгә анда укырга туры килмәде. Күрше Ядегәр авылы мәктәбенә йөреп белем алдык. Югыйсә авылда балалар да күп иде. 5–6 бала үстерүче гаиләләр дә шактый булды.

Алар белән сөйләшә-сөйләшә, без дә чишмәгә төштек. Әйтергә кирәк, халкы чишмәләрен бик кадерли, аның белән горурлана.

– Безнеке кебек матур һәм суы тәмле, шифалы чишмә башка бер җирдә дә юктыр ул. Суын лабораториядә тикшертеп караганнар, составы бик яхшы чыккан, – диде Шакировалар.

Үз өем

Авылның иң өлкән кешесе, 95 яшьлек Газзәбану Вәлиуллина да, башка авылдашлары төсле, җәйгә кызы Әлфия белән гомер иткән авылына кайта. Кышларын исә икенче кызында Алабугада яши.

– Минем чордашлар үлеп бетте инде, кызым. Күп кайгылар күрсәм дә, Аллаһы Тәгалә озын гомер насыйп иткән үземә, – диде ул. – Барысы җиде бала үстердем. Аның дүртесен җирләдем, иремнән калганга да озак еллар узды инде. Авылымның гөрләп торган вакытларын, кыз чакларымны бик сагынам. Рәхәт вакытлар иде ул. Мине бит 19 яшемдә «Беренче театр» уйнаган вакытта урлап алып килделәр кияүгә. Шуннан бирле гел Көектә яшәдем.

Аның сүзләренчә, авыл белән шәһәр арасын таптауларына да ун еллап вакыт узган икән инде.

– Җәйне, гомер иткән Көегем белән очрашуны нык сагынып көтеп алам мин. Кадер-хөрмәттә булсам да, үз өемдә рәхәт инде-е-е, – дип, ирен чите белән генә елмаеп, салмак кына баш кагып куйды Газзәбану әбекәй. – Һавасы да, суы да, түшәкләре дә, кешеләре дә рәхәт инде, кызым. Шәһәрдә дүрт стена арасында ятам бит, монда ичмасам иректә йөрисең! Тавыкларыбыз да, бакчабыз да бар. Кош-кортларның йомыркаларын да үзем чыгып җыям. Авыл гына бетте менә... Нинди зур авылда бер кеше яшәп ятсын әле... Ярый инде, җәен безнең кебекләр җыйнала бераз. Балалар, оныклар кунакка кайтканда да бер гөр килеп алабыз. Анысы да китек күңелгә дәва бирә.

Халкы белән аралашкач, шуны аңладык: Көектә яшәүчесен дә, кайтып кына йөрүчесен дә туган нигезне, әти-әниләрнең рухын саклау нияте берләштерә. Авыл бетсә дә, туган нигезне ничек тә яшәтергә тырышалар әле биредәгеләр.

– Авылыбызны бик нык яратабыз. Матур бит ул! Чишмә суы шифалы, урманнары бай. Ничек яратмаска була аны?! Шушында кайтып, икенче язга җитәрлек көч-куәт, уңай энергетика туплап китәбез без. Гөрләп яшәп яткан башка бер генә авылга да алыштырмас идек, – ди авылдашлар беравыздан.

Көекнең искитмәле гүзәл табигате турында язган идек инде. Аның тагын бер үзенчәлеге бар. Ул – иң читтә урнашкан авыл, юл биредә тәмамлана, моннан ары беркая да барып булмый. Авылның киләчәге шул юл төсле өметсез булса да, аны ярату, туган нигезне саклау хисе мәңгелек булып кала.

Зөлфия Хәлиуллина

ТАБИГАТЬ САТАШТЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанга да яный

Узган шимбәдә бар дөньяның астын өскә китергән давыл аркасында Идел буе федераль округында 10 кешенең гомере өзелде, 76 кеше зыян күрде. Һәлак булучыларның тугызы – Татарстаннан. Давыл йорт түбәләрен кубарып атты. Яшен сугып, йортсыз калучылар, машиналарына зыян килүчеләр дә булды.

Бу фаҗига күбебезгә сабак булды, табигать алдында ни дәрәҗәдә көчсез икәнлегебезне күрсәтте. Арабызда табигатькә чыгып ял итәргә куркып калучылар да шактый. Белгечләр исә табигатьнең мондый көйсезлекләренә ияләнә торырга куша. Баксаң, якын киләчәктә мондый коточкыч давыллар, даими рәвештә кабатланып торып, гадәти күренешкә әверелергә мөмкин икән. Россия Фәннәр академиясе галиме Алексей Карнаухов бу көннәрдә әнә шундый шомлы хәбәр җиткерде. Галим давыл аеруча үз итәчәк төбәкләр исемлеген дә атаган. Алар арасында Татарстан да бар. Безнең республикадан тыш, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Ярославль, Белгород, Калининград, Архангельск өлкәләре, Кырым, Карелия, Коми, Пермь краенда да давыллар еш кунак булачак дип фаразлана.

– Өермә (смерч) һәм торнадолар диңгездә генә түгел, коры җирдә дә күзәтелә ала. Дөрес, Америка белән чагыштырганда, Россиядә бу хәлләр сирәгрәк очрый. Әмма соңгы арада мондый бәла-казалар бездә дә еш була башлады. Климат үзгәрү аркасында алар тагын да ешаячак. Ник дигәндә, температура күтәрелү белән атмосферадагы су парлары да арта. Алар, үз чиратында, өермә, давыллар котыруга сәбәпче була да инде. Россиянең Европа өлешендә өермәләр һәр төбәктә диярлек күзәтелергә мөмкин, – дип фаразлый Карнаухов.

Белгеч сүзе

Анастасия ЯКОВЛЕВА, Республика клиник хастаханәсе табиб-терапевты:

– Һава торышы кисәк үзгәреп торган көннәрдә әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә сизгер кешеләргә аеруча кыенга туры килә. Мондый көннәрдә хроник чирләре булган кешеләрдән сәламәтлеккә аеруча игътибарлы булу сорала. Умырткалык һәм мускуллар (артроз, артрит), йөрәк-кан тамырлары (кан басымы күтәрелү-төшү, ишемия), сулыш (астма, хроник бронхит) системасына бәйле чирләре булган, баш авыртудан интеккән кешеләргә бигрәк тә сакланырга кирәк. Сынган урыннары булган кешеләр, йөкле хатын-кызлар да мондый көннәрдә үзен начар хис итәргә мөмкин. Аларга активлыкны киметергә, ерак юлга чыгудан, очрашу-күрешүләрдән тыелып торырга кирәк. Һава торышындагы үзгәрешләр вакытында кешенең кан басымы уйнарга, буыннары, биле сызларга, кәефе төшәргә дә мөмкин.

Җылыну галәмәте

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев та бу фикер белән килешә.

– Атмосфераның тотрыксызлыгы арта бара. Шуңа бәйле рәвештә андагы дым күләме дә елдан-ел күбәя. Шул сәбәпле соңгы ун елда өермә, давыл кебек хәлләр дә ешрак күзәтелә. Алга таба алар тагын да күбрәк килеп чыгачак. Мондый көчле давыллар хәзердән үк сезонга бер генә түгел, икешәр тапкыр күзәтелә башлады бит инде, – ди белгеч. – Җәй азагына кадәр республикада башка мондый давыллар булмаячак. Ник дигәндә, алдагы көннәрдә антициклон хөкем сөрәчәк. Атмосфера фронтының узуы көтелми. Аномаль җылы булачак. Әмма югары басым болытларга күерергә ирек бирмәячәк.

Тимур Әүхәдиев, соңгы елларда табигатьнең көйсезләнә баруына глобаль җылыну да сәбәпче, дип саный.

– Хәзерге вакытта без, дөрестән дә, глобаль җылыну чорында яшибез. Күптән башланган үзгәрешләр бу. Әмма 1979 елдан башлап Җир йөзендәге глобаль җылынуга бәйле үзгәрешләр аеруча зур тизлектә бара. Моңа табигать тә җавап бирмичә калмый. Анда да киеренкелек арта. Су басулар, корылык, явым-төшемнең кирәк чакта яумыйча, кирәкмәгән чакта төшүе – бар да шуның галәмәте, – ди белгеч.

Быел Тын океандагы су да аномаль җылынган. Соңгы тапкыр бу хәл 2017 елда күзәтелгән булган. Метеокүзәтүләр тарихына ул иң җылы ел дип кереп калган. Белгечләр 2023 елның да тарихта нәкъ шундый аномаль җылы булып истә калачагын фаразлый. Синоптиклар, быел хәтта август, сентябрьдә дә уртача һава температурасы климатик нормадан югарырак булачак, ди.

Тимур Әүхәдиев фикеренчә, чамадан тыш эссегә дә, аннан соң килеп, бар дөньяны туздырган давылына да ияләшергә генә кала. Телефонга килгән шторм кисәтүе турындагы хәбәрләргә дә игътибарлырак булырга киңәш итә ул. Яшерен-батырын түгел: күбебез бу хәбәргә колак салу түгел, аны ачып укырга да иренә бит.

– Давылдан башкача саклану мөмкин түгел. Әмма еракта күк күкрәү ишетелсә, аның сезгә кайчанрак килеп җитәчәген чамалап була. Моның өчен иң элек яшен яшьнәгәннән соң күк күкрәгәнче ничә секунд вакыт үткәнен санарга кирәк. Мисал өчен, 5 секунд вакыт үткән ди. Шуны 300гә тапкырлыйбыз. 1500 чакрым килеп чыга. Димәк, сездән шулкадәр ераклыкта күк күкри дигән сүз. Аның сезгә күпме вакыттан килеп җитәчәген дә шуннан чамаларга мөмкин, – ди белгеч.

Башка булмаячак

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев шулай бер шалтыратуыбызда урып-җыю башланыр алдыннан көчле давыл булачак дип кисәткән иде. Бераз соңарып булса да, чынга ашты бу фараз.

– Көн озынаеп бетеп туктагач, җәйнең иң кызу чагында, урып-җыю башланыр алдыннан ел да шундый давыллар күзәтелә. Быел ул ике атнага соңрак күзәтелде. Әмма быел кайбер урыннарда бигрәк тә көчле дулады ул давыл. Бу һава массаларына бәйле. Быел бит бездә күбрәк антициклон хөкем сөрде, коры булды. Тирә-якта басымнар аермасы никадәр зуррак булса, җил шулкадәр ныграк исә. Элек алай булмаган, диләр. Элек тә мондый көчле давыллар булган инде ул. Мәгълүмат булмагач, кайда нәрсә булганын белмәгәннәр генә, – ди халык синоптигы.

Шулай да быел инде мондый көчле давыллар башка кабатланмас, дип саный Әмир Шәрәфиев. Карнауховның, бездә мондый давыллар даими кабатланып торачак, дигән фикере белән дә килешми ул. Ник дигәндә, табигатьнең дә үз кануннары бар.

– Бездә алай була алмый. Ник дигәндә, табигатьнең цикллары бар. Безнең җирлектә булган һава торышы фәлән ел саен кабатланып тора. Төгәлрәк әйтсәк, табигатьтә 100 елдан соң бөтен нәрсә кабатлана. 33 елдан соң, 11 елдан соң ул тагын якынча кабатлана, – ди Әмир Шәрәфиев.

Халык синоптигы быелгы сентябрь җәйгә охшап киләчәк – җылы булачак, дип фаразлый. Шул рәвешле алтын көз гадәттәгедән озаккарак сузылыр дигән өмет бар.

– Ноябрьдә кыска вакытлы шактый суыклар булып алырга тиеш. Декабрь июньгә охшап киләчәк. Әллә ни җылы да, суык та булмас ул. Әмма менә яңа ел алдыннан шушы июльдәге давыллар кебек көчле бураннар, яки көчле яңгырлар булырга мөмкин, – дип фаразлый Әмир Шәрәфиев.

Хәтергә бәрә

Табигатьтә барган кискен үзгәрешләрне галимнәр Җир шарында барган глобаль җылынуга бәйләп аңлата. Климат үзгәрешләре буенча хөкүмәтара белгечләр төркеменең (IPCC) докладында китерелгән мәгълүматларга караганда, соңгы чирек гасыр эчендә Җир йөзендә уртача һава температурасы 1,5 градуска җылынган. Дөнья океанының биеклеге 20 сантиметрга күтәрелгән. Алга таба да болай дәвам итсә, күп кенә төбәкләр су астында калырга мөмкин, дип чаң суга белгечләр.

Иң гаҗәпләндергәне шул: глобаль җылыну аркасында Җирдәге бар тереклек, шул исәптән кеше организмы да зур үзгәрешләр кичерергә мөмкин икән. Һиндстанның «Sasapost» басмасында дөнья күргән фәнни тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Баксаң, һава җылына барган саен, кеше организмында меланин дигән пигмент күбрәк эшләнә башлый. Билгеле булганча, ул кешенең тән, чәч, күз төсе өчен «җаваплы». Димәк, Җир шары глобаль рәвештә җылына барган саен, кешеләрнең тышкы кыяфәтләре дә үзгәрергә мөмкин. «Глобаль җылыну аркасында акрынлап кешеләрнең тән өлешләре белән баш мие кечерәячәк. Соңгысы аеруча куркыныч. Баш мие кечерәю сәбәпле, кешенең хәтере начарланырга, сөйләмдә тоткарлыклар барлыкка килеп, уку, акыл хезмәте авыр бирелә башларга мөмкин», – дип фаразлый галимнәр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӨСКӘ АГАЧ ТӨШМӘСМЕ?

Мари Элдагы Яльчик күле буенда сигез кешенең гомерен өзгән фаҗигадән соң, урамда барганда, паркта йөргәндә, өскә агач төшмәгәе, дип куркучылар бар. Хәзер андыйларны палаткада ял итәргә чыгу да шикләндерә. Әлеге гарасатның шаһиты булган психолог **Лилия ДӘҮЛӘТШИНА**дан курку хисен җиңү буенча киңәшләр сорадык.

✸ Иң башта нәрсәдән куркуыбызны ачыкларга кирәк. Өскә агач төшүдән куркабызмы, үлемнәнме? Кешеләр табигатькә чыгарга курка икән, үзләренә сорау бирсен. Чатыр эчендә йоклаудан куркамы ул, әллә өстенә агач авуданмы? Бу вакытта үзеңә ничек ярдәм итеп була? Әйтик, куаклыкка, агач булмаган җиргә, кырга чыгарга мөмкин. Әгәр бик каты курыксагыз, табигатькә чыкмый торыгыз.

✸ Ял итәргә чыгарга уйласагыз, һава торышына игътибар итегез. Әгәр көн үзгәргәч, курку хисе барлыкка килә икән, җыенып, тизрәк өегезгә кайтып китегез. Үз психикабызга үзебез генә ярдәм итә алабыз. Монысы – бер. Кайберәүләр исә урманда йөрергә курка. Үз куркуыбыздан курыкмаска кирәк. Ул безгә тормышны саклар өчен бирелә. Әгәр моңа кадәр йөргән паркта башыгызга нидер төшүдән куркасыз икән, тирән итеп сулагыз. «Мин куркам, әмма миңа берни дә янамый», – дип, үзегезне тынычландырыгыз.

✸ Ял итеп кайткач, бары яхшы әйбер турында гына уйлагыз. Әйтик, агачлар тирәсендә йөрдем, саф һава суладым, күләгәдә утырып, канәгатьлек хисе алдым, диегез. Ул чакта яхшы хисләр тискәресен күмеп китәчәк.

✸ Куркуны яки теләсә нинди начар уйларны җиңәр өчен, түбәндәгечә сулыш алуның да файдасы бар. Корсак белән салмак кына сулыш алып, аяк астындагы җирне сиземлибез. Болай итү таянычың барлыгын тоярга булыша. Тыныч вакытта да шуларны эшләп, психиканы һәм үзебезне күнектерә алабыз.

ҺАВА ТОРЫШЫНДАГЫ КИСКЕН ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕ НИЧЕК КИЧЕРЕРГӘ?

✓Йокы вакыты 6–8 сәгатьтән дә кимрәк булмасын!
✓Бүлмәләрне дә җилләтеп торырга онытмагыз.
✓Бу чорда начар гадәтләрдән баш тарту, каһвә, алкогольле эчемлекләр куллану, баллы ризык ашаудан тыелып тору хәерле.
✓Тәүлегенә ким дигәндә ике литр су эчүне дә гадәткә кертегез. Әмма йөрәк-кан тамырлары, бөер авыруы булган кешеләргә суны табиб белән киңәшләшеп кенә эчәргә кирәк.
✓Туклану да игътибардан читтә калмасын. Һава торышы үзгәргән чорда авыр эшкәртелә торган, майлы ризыклардан баш тартыгыз.
✓Йога белән шөгыльләнү, йөзү, саф һавада җәяү йөрү, бакчада эшләү дә файдага гына булачак.
✓Гипертониядән интеккән кешеләр кан басымын, пульсын иртә-кич үлчәп, контрольдә тотарга да онытмасын.

7 август | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». Телесериал 16+
11.00, 03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Соотечественники» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Две жизни Ильяса Дауди 16+
00.25 «Каравай». Поэзия русского костюма 6+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.00 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк 16+
15.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Әдәби хәзинә» 6+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Светлана Ходченкова, Антон Хабаров, Ирина Пегова. «КАЗАНОВА» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «АнтиФейк» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Андрей Мерзликин, Анна Михалкова, Ирина Пегова и Виктор Сухоруков. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Пётр Рыков, Мария Андреева, Ольга Кабо. «ЛОВЕЦ СНОВ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 50 лет легендарному фильму. «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 12.50 Новости
07.05, 16.45, 18.55, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.00, 12.30 Спецрепортаж 12+
10.20 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. 1/8 финала. Прямая трансляция из Австралии
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 Хоккей. Лига Ставок Sochi Hockey Open. «Авангард» (Омск) – Сборная России. Прямая трансляция
16.55 Баскетбол. Товарищеский матч. Мужчины. Россия – Иран. Прямая трансляция из Перми
19.25 Хоккей. Лига Ставок Sochi Hockey Open. ХК «Сочи» – «Адмирал» (Владивосток). Прямая трансляция
22.45 «Тренер. Анатолий Рахлин». Документальный фильм 12+
23.50 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
00.45 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Обзор 0+
01.15 «Лучшие из лучших» 12+
02.45 Новости 0+
02.50 Велоспорт. Чемпионат мира. Трансляция из Шотландии 0+
04.00 Пляжный волейбол. Чемпионат Европы. Женщины. Финал. Трансляция из Австрии 0+
05.00 Пляжное регби. Чемпионат России. Женщины. Финал. Трансляция из Москвы 0+
05.30 Пляжное регби. Чемпионат России. Мужчины. Финал. Трансляция из Москвы 0+

НТВ

04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Юрий Чурсин в остросюжетном сериале «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
00.35 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 «ДИКИЙ» (S) 16+
04.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». Выпускной 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «РАДИ ЖИЗНИ» 16+
19.00 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
23.00 «Понять. Простить» 16+
00.15 «Порча» 16+
00.45 «Знахарка» 16+
01.15 «Верну любимого» 16+
01.45 «Голоса ушедших душ» 16+
02.10 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО». 5-я – 8-я серии 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ». Телесериал. 1-я – 3-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 02.20 «ПОСЕЙДОН» СПЕШИТ НА ПОМОЩЬ» 12+
12.20, 13.25 «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ...» Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.05, 17.15 «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ...» Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». «Миномёты». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Загадки века». Документальный сериал. «Укронацисты. Добровольные помощники вермахта» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПАРАШЮТИСТЫ» 12+
01.15 «СВИДЕТЕЛЬСТВО О БЕДНОСТИ» 12+
03.25 «ВХОД ЧЕРЕЗ ОКНО» 16+
05.25 «Москва фронту». Документальный сериал 16+

8 август | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Секреты казанского чаепития 6+
00.50 «Соотечественники». В. Боков. Не верь словам, не бойся зла 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Ватандашлар» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Габделфәрт Шәрәфиев турында телеочерк 16+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «КАЗАНОВА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «АнтиФейк» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Пётр Рыков, Мария Андреева, Ольга Кабо, Полина Филоненко, Юрий Ицков. «ЛОВЕЦ СНОВ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 50 лет легендарному фильму. Вячеслав Тихонов, Леонид Броневой, Олег Табаков, Леонид Куравлёв, Екатерина Градова. «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ» 12+
04.00 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 14.55 Новости
07.05, 15.00, 23.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.00 Специальный репортаж 12+
10.20, 00.45 «География спорта. Ростов-на-Дону» 12+
10.50 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. 1/8 финала. Прямая трансляция из Австралии
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.30 Футбол. FONBET Кубок России. «Урал» (Екатеринбург) – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
18.15 Футбол. FONBET Кубок России. «Рубин» (Казань) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
20.30 Футбол. FONBET Кубок России. «Спартак» (Москва) – «Пари НН» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
00.15 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Обзор 0+
01.15 «Лучшие из лучших» 12+
02.45 Новости 0+
02.50 Велоспорт. Чемпионат мира. Трансляция из Шотландии 0+
04.00 Пляжный волейбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Финал. Трансляция из Австрии 0+
05.00 Стрельба из лука. Чемпионат мира. Трансляция из Германии 0+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Остросюжетный сериал «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
00.35 «Основано на реальных событиях» 16+
01.20 «ДИКИЙ» (S) 16+
04.15 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». Чужая девочка 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ОБМАНУТЫЕ НАДЕЖДЫ» 16+
19.00 «ХРУСТАЛЬНАЯ КОРОЛЕВА» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.45 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.45 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО». 9-я – 12-я серии 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.45 «ГЕРОЙ 115». Документальный фильм 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 02.15 «РАССЛЕДОВАНИЕ» 12+
12.40, 13.25, 15.05 «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-2». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25, 17.15 «НА УГЛУ, У ПАТРИАРШИХ-2». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Снайперские винтовки». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Дело о беспилотниках: украинский детектив с западным акцентом» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «БЕЗ ОСОБОГО РИСКА» 12+
01.00 «КЛЮЧИ ОТ НЕБА» 12+
03.30 «ПАРАШЮТИСТЫ» 12+
05.00 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа». Документальный фильм 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен **Косач** Динара Илдар кызы, **Косач** Андрей Владимирович **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ата-ана даны» ордены** белән бүләкләнделәр.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Аш-су» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Исламова** Әлфизә Мостафа кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Россия фәннәр академиясе һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең кафедра мөдире **Бодрова** Резедә Әхмәт кызына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшенә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең хирургия авырулары кафедрасы мөдире **Красильников** Дмитрий Михайлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе **Хәбибуллин** Альберт Галимҗан улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе җитәкчесе урынбасары **Хамматов** Фәннур Гаптелбәр улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе **Бакиров** Газинур Тәлгать улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

Каләм тотып кулларга...

Каникулның соңгы ае – августка аяк бастык. Педагогия фәннәре кандидаты, педагог-психолог Юлия Челышева ике айлык ялдан соң балаларны мәктәпкә әзерли башларга тәкъдим итә. Һәм сүз каләм, дәфтәр, форма һәм башка кирәк-ярак җыю турында түгел, ә акыл эшчәнлеге турында.

Мәскәү дәүләт педагогика университеты галимнәре балалар өч түгел, ике ай гына ял итеп, һич югы, каникулның соңгы көннәрендә өйрәнгәннәрен искә төшерсә, сентябрьдән уку процессын башлап җибәрү күпкә җиңелрәк булачак дип саный. Баш мие дә – мускул бит, аны да эшләтеп торырга кирәк ягъни.

Мәктәп яшендәге балалары булган әти-әниләргә нәрсәгә игътибар итәргә?

Хисап. Психологлар хәзерге балаларның тәнкыйди, мантыйкый фикерләү сәләтен түбән дип бәяли. Ә бу сәләтне үстерергә математика ярдәм итә ала. Әмма җәйге көннәрдә математик биремнәрнең артык катлаулыларын түгел, җиңел мәсьәләләр чишү дә җитә. Балада математикага карата нәфрәт уянырлык булмасын.

Уку. Бу очракта балага үзенә ошый торган әдәбиятны сайларга рөхсәт бирегез. Кычкырып уку да файдалы. Беренчедән, бу баш миендәге ярымшарлар арасындагы элемтәләрне формалаштыра. Икенчедән, балагызның кызыксынып тыңлыйсы икән, сезнең арадагы элемтәләр дә ныгыячак.

Язу. Баланың куллары каләм һәм язуны бөтенләй онытып бетермәскә тиеш. Әмма бу очракта да аны кызыксындыра белергә кирәк. Каллиграфия турында сөйләргә, язуны матурлау күнекмәләренең кызыклыларын табып, аларны өйрәтергә була. Я булмаса, балагызга язу аша кешенең холык-фигылен танып булуы турында сөйли аласыз. Кыскасы, нинди дә булса кызыгын табып, вакытны файдалы да, күңелле дә итеп уздырырга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТИР ГЕНӘ, ДИМӘ

Кеше елына якынча 1052 литр тир бүлеп чыгара. Галимнәр шулай ди. Шул рәвешле кешене гомер буе озата баручы күренеш бу. Беренче карашка гадәти хәл кебек тоелса да, тирләү чир билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә табиблар. Кайсы очракта кешенең чамадан тыш тирләве норма санала да кайчан чаң сугарга кирәк?

Шул сораулар белән Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина ГАЛИУЛЛИНАга мөрәҗәгать иттек.

:: Тир турында без нәрсәләр белеп торырга тиеш?

– Тир ярдәмендә организм әйләнә-тирәдә үзгәреп торган шартларга яраклаша. Шуңа күрә кешенең эссе көнне яки тынчу бүлмәдә тирләве – гадәти хәл. Стресс кичергәндә, артык ачы, тәмләткечләргә бай ризык ашагач та тир бүленеп чыгарга мөмкин. Хатын-кызларның климакс вакытында, яшүсмерләрнең үсеш чорында чамадан тыш тирләве – шулай ук табигый күренеш. Ник дигәндә, бу чорда гормоннар, эндокрин система җитди үзгәреш кичерә. Әгәр кеше тик торганда да тирли икән, шикләнергә җирлек бар. Бу очракта тирләү гадәти күренеш кенә түгел, чир буларак бәяләнә. Медицинада ул гипергидроз дип атала.

:: Бу чир ни сәбәпле пәйда була соң?

– Йогышлы авыру кичергән, эндокрин система, неврологиягә бәйле авырулары булган кешеләр даими рәвештә тирләүчәнгә әйләнергә мөмкин. Бөер, бавыр, ашказаны асты бизе кебек эчке әгъзалары авырткан кеше дә сәбәпле-сәбәпсез тирләп тора ала. Кайбер көчле дарулар да организмга шулай тәэсир итәргә мөмкин.

:: Тирләүне дәвалап буламы?

– Чамадан тыш тирләүне дару белән генә дәвалап бетереп булмый. Андый чакта, гадәттә, табиб витаминнар, седатив препаратлар, тынычландыручы дарулар яза. Артык каты тирләүдән интеккән кешегә составында салицилат, триклозан, цинк кебек дәвалаучы матдәләр булган дезодорантларга өстенлек бирергә кирәк. Заманча косметология мөмкинлекләреннән файдаланучылар да бар. Күпләр, тирләүдән котылу өчен, култык астына махсус укол (диспорт) ясата. Уколның файдасы ярты – бер елга җитә.

:: Тирләмәс өчен, ничек тукланырга?

– Иң беренче чиратта, ачы, тозлы, баллы, кыздырылган, кайнар ризык ашаудан тыелып торсаң, яхшырак булачак. Салкын су эчү дә зыянга гына. Тирдән котылу өчен фастфуд, газлы эчемлекләрдән дә баш тартырга туры киләчәк. Ачы борыч, сарымсак, нерв системасын ярсытып, көчле тир бүленеп чыгуга китерә. Ит һәм балыкның да майсыз төрләрен генә ашау хәерле. Яшелчә, җиләк-җимеш тә читтә калмасын. Рационыдагы продуктлар В, Е витаминнарына, кальцийга бай булырга тиеш. Ник дигәндә, тирләгәндә организм, нигездә, нәкъ мене шушы файдалы элементларны югалта. Карабодай, кишер, кузаклылар, кычыткан да тирләүне киметә.

:: Исе дә үзгәрергә мөмкин бит әле...

– Организмыбыздагы токсиннар ашказанату-эчәклек тракты, бәвел юлы аша да чыгарга мөмкин. Алар начар эшләсә, тыгылган булса, токсиннар тән тиресе аша тир рәвешендә бүленеп чыгачак. Кайбер даруларны эчкән вакытта тир исе кискен үзгәрергә мөмкин. Кайчак организмда кайбер ферментлар бүленеп чыкмый. Нинди дер бер продукт организмга эләкәч, шушы ферментлар ярдәмендә эшкәртелә алмый һәм ул үзеннән-үзе токсинга әверелә. Тән тиресе аша тир ярдәмендә бүленеп чыгып, шулай ук тир исен үзгәртә ала. Мисал өчен, сарымсак та тир исенә йогынты ясый.



vk.com

НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

✓ Чамадан тыш тирләүдән интеккән кеше, иң беренче чиратта, табибка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Эндокринологка мөрәҗәгать итү дә комачауламас. Кардиолог, невролог ярдәме дә таләп ителергә мөмкин.

✓ Гомуми кан анализы тапшырып карарга кирәк. Бәлки организмга инфекция эләккән, ялкынсыну башлангандыр?

✓ Чамадан тыш тирнең ни сәбәпле килеп чыгуын ачыклагач кына дәвалауга керешергә мөмкин.

✓ Тирләп интеккәндә имән кайрысы, шалфейлы су белән коену да яхшы. Контраст душ керсәң дә файдалы.

✓ Чамадан тыш тирләп интектергән урынны содалы су белән сөртсәң дә, нәтиҗәсе озак көттермәс. Ул тудырган селтеле тирәлектә авыр тир исе китереп чыгарган гөмбәчек, бактерияләр үрчеми. Ромашка төнәтмәсе дә шундый ук нәтиҗә бирәчәк.

✓ Тирләмәс өчен, табигый тукымадан тегелгән киемнәр генә киярга киңәш ителә. Шәхси гигиена кагыйдәләрен дә истән чыгарырга ярамый.

Абау!

КАНЫҢ КУЕРМАГАНМЫ?

Кан куеруын ничек аңларга һәм нинди ысуллар кулланырга? Бу уңайдан телеграм-каналда танылган онколог һәм хирург **Иван Карасев** киңәшләр биргән.

▶ Кан, гадәттә, организмга су җитмәгәндә куера. Шул сәбәпле иммунитет та начарлана, куе үт хасил була. Бу исә, үз чиратында, үт куыгында ташлар барлыкка китерергә мөмкин.

▶ Әгәр авызга нәрсәдер кабарга кирәклеген тойсагыз, димәк, организмга су җитми дигән сүз, ди табиб. Бу очракта ашарга түгел, ә су эчәргә кирәк. Тамак ачыкса, кеше аны ялгыш тоячак һәм ул ашерен сусау рәвешендә булмаячак.

▶ Һәр иртәне бер стакан җылы су эчүдән башларга кирәк. Су эчә торган гадәтегез булмаса, суны нормага кадәр җиткергәнче аз күләмдә эчәргә кирәк.

Табигать даруханәсе

Кычыткан – дәва

Кычыткан – бик күп авырулардан шифа. Ул кандагы эритроцитларны арттыра, кан составын көйли, шикәрне киметә һәм витаминнарга баета.

✓**Буын, теш, күз өчен.** Ике аш кашыгы кычыткан, 1әр аш кашыгы тут агачы, караҗиләк, каен җиләге яфракларын ваклагыз, кушып болгатыгыз, 1 аш кашыгы катнашмага 1 стакан кайнар су салып, суынганчы төнәтегез һәм бер ай дәвамында көнгә өч тапкыр 50шәр миллилитр эчегез. Бу буыннар, мускул, теш авыртканнан дәва бирә, күрүне, тирене яхшырта.

✓**Йөрәк авыртканда.** Кычытканны ваклап, ярты литрлы банкага тутырырга, өстенә аракы коярга, көн яктысында бер тәүлек төнәтергә кирәк. Соңыннан бер атна караңгы урында тотып, ике кат марля аша сөзегез, өч атна дәвамында, ашарга ярты сәгать кала, көнгә өч тапкыр 1 чәй кашыгы күләмендә эчегез. Төнәтмәне суыткычта саклагыз.

✓**Тоз утырганда, подагра һәм остеохондроздан.** Моның өчен 1 аш кашыгы кычыткан согын, кычыткан тамырлары төнәтмәсенә кушып, көнгә дүрт тапкыр эчәргә кирәк. Төнәтмә ярты литр суга 2 аш кашыгы исәбеннән ясала. Дәвалау 1,5–2 ай дәвам итә, бу вакытта диета да сакларга кирәк була. Кычыткан согы чиста яки кушылма рәвешендә яралар вакытында, пешкәндә, җәрәхәт алганда, анемия, диабет, бавыр, бөер чирләре, гинекологик авырулар, бронхиаль астма, туберкулез, коклюш, эпилепсия, күзән җыеру, невроз, теләсә кайсы онкологик авырулар вакытында файдалы.

Шунысын да онытмагыз: гипертония, атеросклероз авыруларыннан интеккән кешеләргә, аналыктан кан киткәндә кычытканнан ясалган төнәтмәләрне кулланырга ярамый.

Киңәш-табыш

Сару кайнаса

Сару кайнап интектерә икән, туклану рәвешен үзгәртергә кирәк, ди белгечләр.

- Көндәлек рационга җимешләр кертегез. Мәсәлән, кавын, банан…
- Иртән солы яки дөге боткасы ашарга.
- Оеган сөт, катык, кефир эчегез.
- Ромашка төнәтмәсен иртән чәй урынына кулланырга мөмкин.
- Төйгән бәрәңге дә сару кайнауны баса.
- Ач карынга кәһвә эчүдән, төрле соклардан баш тартыгыз. Иртән уянгач, бер стакан су эчеп куюдан да яхшысы юк. Ярты сәгатьтән соң солы боткасы, банан ашарга мөмкин.
- Әфлисун, мандарин, алманы төшке аштан соңга калдырыгыз.

Валентина СЕМЕНОВА

КЫЗУ МӘЛ

Җәйнең соңгы аенда бакчачылар, гүя бал кортлары, мең дә бер мәшәкатькә чума. Кыяр-помидор, алма-груша, сливаларның уңышын җыеп, тозлап-маринадлап, компот ясап, варенье кайнатып куюдан тыш, әле тагын кайбер культураларны утырту, туфракны, агач-куакларны тәрбияләү вакыты да бу.

Август аендагы иң мөһим эшләр турында «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА искә төшерде.

vk.com

– Тагын бер тапкыр редис утырту өчен уңайлы ай. Быел августның беренче атналары эссерәк килү сәбәпле, бу эшне ай урталарына күчерү әйбәт булачак. Көзгә таба утыртылган редис аеруча сусыл, тәмле була, тиз картаймый, чәчәккә китми. Бушап калган түтәлләргә яшел тәмләткечләр: салат, укроп, петрушка кебек үләннәр чәчегез. Алар тиз үсеп китәчәк һәм көзгә кадәр менә дигән уңыш бирәчәк. Моннан тыш ачы торма, шалкан, борчак (тиз өлгерешле сортларын) чәчәргә мөмкин. Август – Пекин кәбестәсен утырту өчен бөтенләй дә идеаль ай. Гөрләп үсеп китәчәк!

Шул ук вакытта туфракны савыктыра башларга кирәк. Моның өчен бушап калган түтәлләргә горчица, арыш, люцерна ише сидератлар чәчүдән дә яхшысы юк. Әйтик, горчица каты кортларга (проволочник) тискәре йогынты ясый. Ә менә люцерна кызыл балчыклы бакча өчен файдалы: туфракны көпшәкләндерә һәм азотка баета. Сидератны комлы туфракка чәчү дә әйбәт: кибү-ярылудан саклый, ныгыта һәм кирәкле матдәләргә баета.

Әлбәттә, чүп үләннәргә каршы көрәшүне дә дәвам иттерәбез. Тик йолкып ташлаганчы, нәрсә икәненә игътибар итегез. Чөнки алар безгә әйбәт кенә мәгълүмат бирә. Әйтик, алабута туфракка органик ашлама, ягъни тирес җитмәгәнлекне аңлата. Наратбаш (хвощ), ромашка туфракның әче булуын – известь кертүне таләп итүен күрсәтә.

Бакча җиләге утыртабыз

Августта җимеш агачлары киләсе елда уңыш бирергә әзерләнә башлый. Шуңа күрә аларны фосфор һәм калий белән тукландырырга кирәк. Ә инде август ахыры – сентябрь башында чия, карлыган, артыш (можжевельник) кебек куакларны утырту әйбәт.

Моннан тыш виктория үсентеләрен күчереп утырту өчен иң уңайлы ай бу. Мыекчалары бу вакытка инде тулысынча җитлеккән була. Бакча җиләген өч-дүрт елга бер тапкыр яңа урынга күчереп утыртырга кирәк. Сайлап алынган урынны казып, торф, компост черемә кертергә һәм яхшылап тигезләргә. Күп итеп су сибәргә. Бер атнадан соң утыртырга. Бу вакыт эчендә органик ашлама туфракны кирәкле барлык матдәләр белән баетачак. Мыекчаларны көрәк белән сак кына казып алырга һәм һәрбер чокырга берәр генә мыекча утыртырга кирәк.

Күпьеллык чәчәкләр дә игътибар сорый торган вакыт. Суганчалы үсентеләрне, чалмабашны (пион), бүлеп, күчереп утыртырга, роза куакларын корыган чәчәкләре һәм ботакларыннан арындырырга кирәк.

Корылык күзәтелмәсә, августта кыяр, кәбестә, кишер, чөгендергә генә су сибәбез. Бигрәк тә кишер түтәлләре игътибар сорый. Вакытында су сипмәсәң, тамыразык ярылачак һәм кәкре-бөкре булып үсәчәк.

Кышка әзерлек

СУГАННЫ КАЙЧАН АЛЫРГА?

Вакытыннан алда җыйсаң, өлгереп җитмәгәнлектән, төрле корткычлардан уңышка зыян килергә мөмкин. Соңга калсаң, кабыгы әрчелә, тамырлана башлый һәм озак сакланмый. Суган җыярга вакыт җитүнең төп билгеләре:

- Сабаклары саргаеп кибә һәм түтәлгә ята башлый. Яшелчәне гадәттә хәзер: айның башыннан урталарына кадәр җыеп алалар.
- Математик исул белән дә санап чыгарырга мөмкин. Утыртканнан соң 68–83 көндә өлгерә. Шулай ук җәйнең ничек килүенә дә игътибар итәргә кирәк. Әгәр салкынча булып, яңгырлар еш яуса, суганның үсеше озаккарак сузыла. Шуңа күрә җыеп алу вакыты да күчерелә. Ләкин артык соңга калырга да ярамый, чөнки яңгырлар вакытында яңа тамырлары барлыкка килергә мөмкин.
- Суганны дөрес җыярга кирәк. Аны коры көнне алырга, кирәк булса, бераз көрәк белән казып җибәрергә мөмкин. Йолкыгач, балчыгыннан арындыру өчен, җиргә бәреп какмагыз, юкса яшелчәгә зыян киләчәк. Суганнарны кояшта әйләндерә-әйләндерә киптерергә киңәш ителә. Соңыннан җиләс урынга күчереп, берничә көн тотасы. Әгәр һава торышы мөмкинлек бирсә, кипкәнче, түтәлдә калдырсаң да була. Бу очракта төнгә өстенә берәр әйбер ябып калдырырга кирәк.
- Кыякларын төбеннән үк кисеп ташларга ярамый, чөнки туклыклы матдәләр суганның өлгереп җитүенә ярдәм итә. Соңыннан юан, ачык муентыклы, төпләре зарарланган суганнарны аралыйсы гына кала.

Укучы киңәше

ЙОЛКЫП ТАШЛЫЙМ

- Кәбестә күчәне эрерәк үссен өчен, аскы яфракларын өзеп ташлыйм. Ник дигәндә, алар яшелчәнең туклыклы матдәләрен генә суырып утыра.
- Шулай ук көнбагышны да аскы яфракларыннан чистартам. Болай эшләгәндә, уңышы мулрак, орлыклары эрерәк булачак.
- Август урталарында борыч һәм баклаҗанның барлык чәчәкләрен өзәм: алар инде барыбер уңыш бирергә өлгермәячәк.

Гүзәл ШӘРӘФЕТДИНОВА.
Балык Бистәсе

Тәмле булсын!

«Анкл бенс»

Гүзәлия ШӘКҮРОВА рецепты

Кирәк: 2 кило ташкабак, 5–6 татлы борыч, уртача зурлыктагы 10 кызыл помидор, 10 баш суган, 1 стакан үсемлек мае, 1 аш кашыгы уксус, 1 аш кашыгы тоз, 1 стакан шикәр комы, ярты литр томат пастасы (су өстәп, 1 литрга җиткерергә).

Ташкабакны кабыгыннан чистартып – шакмаклап, суганны – божралап, татлы борычны – озынча итеп, помидорны эрерәк кисәкләргә турыйбыз. Үсемлек мае, томат пастасы, тоз өстибез. Шикәр комы һәм аш серкәсе салып, 40 минут пешерәбез. Чиста банкаларга тутырып, 10 минут «су мунчасы»нда стерильләштерәбез.

Җәйге рагу

Нурсәнә МОТЫЙГУЛЛИНА рецепты

Кирәк: уртача зурлыктагы 1 ташкабак, 1 баш суган, 3 помидор, 1 кишер, 1 татлы борыч, 4 бәрәңге, 2 тырнак сарымсак, 50 мг үсемлек мае, тәмен-чә тоз, борыч.

Суганны ваклап турыйбыз, кишерне эре тишекле угыч аша чыгарабыз. Үсемлек маена салып, яшелчәләрне кыздырабыз. Бәрәңгене әрчеп, эрерәк кисәкләргә турыйбыз да суган һәм кишер янына өстәп кыздырабыз. Татлы борыч һәм әрчеп туралган ташкабак өстибез. Болгата-болгата, барысын бергә 15 минут чамасы кыздырабыз. Шуннан соң рагуга помидор (өлешләп туралган), сарымсак (изеп), тоз, борыч өстибез. Барысын бергә болгатып, сүрән утта яшелчәнең үз согында 15–20 минут пешерәбез. Уттан алып, капкачын ачмыйча, бераз тотабыз. Җиңел генә әзерләнелә торган бик тәмле җәйге гарнир бу!

Белсәң, зыян итмәс

✓ Соус ясау өчен коры ак шәрабыгыз юк яки аны бөтенләй кулланмыйсыз икән, бераз гына аш серкәсенә ике кисәк шикәр салып эретегез. Мондый үзенчәлекле серкә теләсә кайсы соуста ак шәрабны алыштырачак.

✓ Сары майдан (эретелгән атланмай) күгәргән тәм килсә, болай эшләгез. Майга салкын су һәм 1 чәй кашыгы чәй содасы өстәп, әйбәтләп болгатыгыз. Бераздан, суын түгеп, 1 стакан сөт (1 кило майга) салыгыз һәм майны яңадан эретегез. Сары май янә тәмле булачак.

КӨН ДӘ МЕҢ СОРАУ

«Фәрештәләр, гыйлем алучы кешегә кылган гамәленә ризалык белдереп, канатларын җәяләр», – диелә хәдистә. Белмәгәнне белергә омтылу хас кешегә. Тормыш иткәндә еш кына теге яки бу сорауга җавап эзләп, дингә мөрәҗәгать итеп, белем эстибез.

Бу юлы укучыларыбызны борчыган сорауларга Саба районының Сатыш авылы имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ җавап бирде.

?Кабер янына килгәч, нинди дога уку хәерле?

Фәльянур АРСЛАНОВА

– Кабер янына килгәч, «Мүлк», «Ясин», «Фатыйха», «Ихлас», «Әл-Кәфирун» сүрәләрен укып, дога кылырга мөмкин. Доганы үз телебездә кылабыз. Йә булмаса Ибраһим (г.с.) догасын укырга була: «Әй Раббыбыз! Хисап соралачак кыямәт көнендә мине, ата-анамны һәм бөтен мөэминнәрне гафу әйлә».

?Бала тугач, корбанны кайчан чалырга, кайчан бәби чәе уздырырга?

Зәринә ЗИННӘТУЛЛИНА

– Бу сөннәт корбан санала. Икенче төрле Гакыйка корбаны дип атала. Бу – саваплы эш. Ир балага – ике, кыз балага бер сарык чалына. Ул Корбан гаете көннәрендә чалынырга тиеш түгел. Бала дөньяга килгәч, 7, 14, 21 нче көннәрдә корбан чалырга мөмкин. Бу вакытта ук мөмкинлек юк икән, корбан чалу эшен бала балигълыкка җиткәнче башкарырга рөхсәт ителә.

?Кеше аңлы рәвештә бик күп тапкыр зина кылса, аның Аллаһтан гафу сорарга хакы бармы?

Исемем редакция өчен генә

– Аллаһы Тәгалә: «Зинага якын да килмәгез!» – ди. Ягъни зинага якын китерә торган гамәлләр кылмаска кирәк. Әйтик, никахсыз ир белән хатынның кулга-кул тотынуы, бер бүлмәдә калуы һәм башкалар. Әмма мондый гөнаһ кылган кешенең Аллаһы Тәгаләдән гафу сорарга мөмкинлеге бар. Аллаһы Тәгалә бөтен гөнаһны, хатаны ярлыкый. Гафу сорарга барыбыз да хаклы. Әмма инде бу кешегә иң элек зина кылуын да туктатырга кирәк.

?Ни өчен сул кул белән ашарга ярамый?

Ренат Г.

– Сул кул белән шайтан ашый. Шуңа да, кем дә кем сул кул белән ашаса, ул – шайтанны ашатучыдыр. Без уң кул белән ашарга тиеш.

?Якын кешем мине туена чакыра. Анда хәрам әйберләр дә булачак икән. Ул үпкәләмәсен дип, мин бу чакыруны кабул итә аламмы?

Зөлфирә Ж.

– Хәрам эчемлек, ризык булган мәҗлесләргә бару – мөселман өчен тыелган гамәл. Кайсы очракта рөхсәт ителә? Хәрам ризык, эчемлекләр булган өстәлдә утырган очракта, аларны өстәлдән алып куюны сорап, табында аны кулланмасалар, барырга мөмкин. Гадәттә, болай эшләмиләр инде. Димәк, мәҗлескә чакырган кешене алданрак котларга мөмкин. Намазлы, түбәтәйле, яулыклы кешеләр мондый мәҗлесләрдә катнашса, алар начар үрнәк күрсәтә дигән сүз. Оештыручыларга хәрам ризык, эчемлек белән узган мәҗлеснең бәрәкәтсез булуын ипле генә итеп аңлату да хәерле булыр. Аллаһы Тәгалә: «Начарлыкны туктаткан кешегә әҗер-савап булыр», – ди.

?Телефон, компьютер һәм башка төрле җайланмаларның экранына Аллаһ исемен кую рөхсәт ителәме?

Әмир

– Аллаһы Тәгаләне искә төшерү өчен тора икән, куркынычы юк. Әмма Аллаһ исемен телефонга ябыштырып куеп, аның белән, әйтик, бәдрәф, мунча ише җирләргә керсәк, бу дөрес түгел. Аллаһы Тәгалә исеменнән кала да гаджетлар өчен матур

ru.freepik.com

рәсемнәр күп бит. Аллаһ исеме, шәмаилләр чиста җирдә торырга тиеш.

?Мөслимәләргә матурлык салоннарына йөрергә ярыймы?

Гүзәл

– Дин хөкемнәрен бозмый, гөнаһ гамәлләр кылынмый икән, бу очракта рөхсәт ителә.

?Әчеп үлгән, үз-үзенә кул салган кешеләргә күмгән вакытта дога кылынмый, дип ишеткәнем бар. Бу дөресме?

- ✓Иртәнге аш яки полдник бәясе – 35 сум (сөт ризыклары, пешкән әйбер һәм эчемлек; кондитер эшләнмәсе, пешкән әйбер һәм сөт ризыгы).
- ✓55 сумлык комплекс та бар. Монда өч төрле вариант тәкъдим ителә. Аш ашыйсыңмы, гарнирмы, башкасынмы – үзең теләгәнен ашарга мөмкин.
- ✓79 сумлык менюда салкын кабымлык, җиләк-җимеш, балык, аш һәм башкасы каралган.
- ✓16 сумлык аш та бирелә.

Туклану мәсьәләләренә кагылышлы сораулар туганда, 88002343388 номерына шалтыратырга мөмкин.

СУКМАГЫҢНЫ БУТАМА!

КЫРГЫЙ ҺӘМ ЙОРТ ХАЙВАННАРЫН ТАПТАТКАН ӨЧЕН НИНДИ ҖӘЗА КӨТӘ?

Global Look Press / Arne Dedert

Машина тәгәрмәче астында калган кыргый һәм йорт хайваннары катнашында юл-транспорт һәлакәтләре турында әледән-әле ишетеп торабыз. Мондый хәлләр еш кына автомобиль хуҗасы өчен матди һәм рухи мәшәкать тудыра. Узган ел республикада кыргый хайваннар катнашында 158 авария булган иде. Тәгәрмәч астына, гадәттә, поши һәм кабан дуңгызлары эләгә. Автомобиль йөртүче мондый хәлдә калса, аңа нишләргә? «ВТ» шул сорауга җавап эзләде.

Гаепсездән гаепле

Кыргый җәнлекләр катнашындагы юл фаҗигаләренең күпчелек өлеше май – октябрь айларына туры килә, дип искәртә белгечләр. Монда барысы да берьюлы туры килә инде: хайваннарның биологик ритмы да (көчеш, үрчү чорлары), машиналар агымының көчәюе дә. Юл, җир, тозелеш эшләре, урманнарны кисү дә җәнлекләрнең трассага чыгуына китерә. Эссе көннәрдә су, ышык эзләп йөрүләре дә ихтимал.

– Кичке якта эшләр буенча Казаннан Апас районына кайтырга туры килде. Төнлә кире шәһәргә юл тоттым. Яшермим, тиз бардым, әмма кагыйдәләрне бозарлык дәрәҗәдә түгел. Кинәт кенә машинама куян килеп бәрелмәсенме! Мин аның кайдан атылып чыкканын да күрми калдым, әйтерсең лә кемдер аны кинәт кенә юл уртасына чыгарып куйган да минем тәгәрмәч астына керергә кушкан! – дип сөйләде бу елның май аенда күңелсез хәлгә юлыккан Илфат Галиев. – «Куян гына ич инде ул», – дияргә ашыкмагыз! Машинаның бамперы, ике радиаторы, «туманник» һәм рәшәткәсенә зыян килде шул йомшаккайдан. Ремонт якынча 55–60 мең сумга чыкты. Бу – машина запчастьларына тотылган акча. Аны бушка алмаштырмыйлар, төзәтмиләр бит. Эш өчен дә түлисе. Моның өчен тагын якынча 20 мең сум китте.

НИЧӘ СУМ ТҮЛИСЕ?

Хайван төре	Штраф күләме (сумнарда)
Поши, себер тау кәҗәсе, сарыкүгез (овцебык)	80000
Кабан, Төньяк кыргый боланы	30000
Затлы болан	70000
Сайгак, туры, тимгелле болан, кабарга, нәфис болан	60000
Муфлон, кыр кәҗәсе, серна	40000
Чубук	100000
Зубр белән бизон гибриды	180000
Аю	60000
Бурсык	12000
Харза, байбак, кондыз, сусар	6000
Селәүсен	40000
Бүре, төлке, шакал, янут, янутсыман эт	200
Кыргый песи, куян, йорт куяны, чәшке, корсак, ак төлке	1000
Тиен, ас, ләтчә, су күсесе, борындык	500
Сукыр тычкан, су тычканы, йомран, әрлән	100
Суер	6000
Көртлек	2000
Каз, казарка	1000
Үрдәк, күгәрчен, кыр тавыгы, боҗыр	600
Бүдәнә, бибек, урман күгәрчене	200

Искәрмә: Кызыл китапка кертелгән җәнлекне бәрдерү штраф күләмен бермә-бер арттыра!

Нишләргә?

Иң тәҗрибәле, юлларда тәртипле йөри торган машина йөртүче белән дә мондый хәл килеп чыкмас дип кем әйтә ала?! Мондый очракта нишләргә? Башкаладагы бер экспертиза үзәге белгечләре шул җәһәттән автомобиль йөртүчеләр өчен киңәшләр белән уртаклашты.

Ничек кенә гади яңгырамасын, иң элек тынычланырга кирәк. Шундук машинадан чыгу да ярамый. Хайванның нинди хәлдә булуын белмисең бит. Шок кичергән җан иясе, ачуы артып, автомобиль хуҗасына сикерергә, хәтта үтерергә дә мөмкин! Шуңа да бераз көтеп тору зыян итмәс. Әллә ни зыян күрмәгән җәнлек урыннан торып китәргә дә мөмкин.

Күңелсез хәл килеп чыккан икән, ЮХИДИ хезмәтенә шалтырату сорала. Юл-транспорт һәлакәтен теркәргә кирәк чөнки.

Шуннан соң түбәндәгечә эш итәсе:
- «аварийка» кабызасы;
- махсус юл билгесен куясы;
- авариягә бәйле нәрсә бар, шуларны урыннарында саклыйсы;
- сәламәтлеккә зыян килгән очракта, ашыгыч ярдәм машинасын чакыртасы;
- авария урыныннан китмәскә;
- авария урынын фото-видеога төшерәсе, алар юл-транспорт һәлакәтен теркәгән вакытта кирәк булырга мөмкин;
- зыян күргән хайванны урыныннан кузгатырга, күчереп куярга ярамый! Хәтта ярдәм итәргә теләсәгез дә;
- инспекторлар килгәч, аларга әлеге күңелсез хәл турында барысын да бәйнә-бәйнә сөйләргә;
- авария хакында иминият компаниясенә хәбәр итәргә.

Әгәр мондый юл-транспорт һәлакәтендә машина йөртүчене гаепле дип табалар икән, матди зыянны аның өчен иминият компаниясе каплаячак. Әлбәттә, авария вакытында полис гамәлдә булса.

Түләмәскә ярыймы?

Автомобиль хуҗасы үзенең гаепсез булуын исбат итеп карый ала. Моның өчен автотехник экспертиза белгечләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар хайванны бәрдерми калу мөмкинлеге булмавын ачыклый алса, машина йөртүче җаваплылыктан азат ителәчәк. Экспертизаны Дәүләт автоинспекциясенә гариза язып сорарга мөмкин.

Шунысын да искәртергә кирәктер: иминият полисы булып та, анда җәнлекләр катнашында авария очрагы күрсәтелмәгән икән, машина хуҗасы автомобилен үз хисабына төзәтәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч сүзе

«ДӘҮЛӘТ ТӘ ЗЫЯН КҮРҮЧЕ БУЛЫП САНАЛА»

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– Хайваннар катнашындагы юл-транспорт һәлакәтләре, автомобиль катнашындагы башка юл-транспорт һәлакәтеннән аерылмый, ягъни авария очрагында башкарыла торган гамәлләр тәртибе бер үк булачак.

Авария очрагын тиешенчә рәсмиләштерергә кирәк, димәк, юл-транспорт һәлакәте булган урыннан китәргә ярамый. Моның өчен Россия Административ хокук бозулар кодексының 12.27 маддәсенең 2 өлеше нигезендә җәза каралган. Ягъни машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм ителү яисә 15 тәүлеккә кулга алу куркынычы яный дигән сүз.

Юл-транспорт һәлакәтен рәсмиләштерү өчен инспекторларны чакырырга кирәк. Шуны аңласак иде: хайваннар, Россия Гражданнар кодексы буенча, милек булып санала. Йортныкылар – шәхси, ә кыргыйлары – дәүләтнеке. Кыргый хайван белән юл-транспорт һәлакәте очрагында зыян күрүче як булып Россия саналачак. Димәк, машина йөртүче дәүләткә китерелгән зыянны капларга тиеш булып чыга. Юл-транспорт һәлакәте дөрес итеп рәсмиләштерелгән һәм ОСАГО полисы булган очракта, китерелгән зыянны иминият компаниясе каплаячак.

Кыргый хайваннар катнашындагы авария очракларында матди зыянны исәпләү методикасы Россия Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2011 елның 8 декабренә караган 948 номерлы боерыгы белән расланган. Ә йорт хайваннары белән юл-транспорт һәлакәте булган очракта матди компенсация күләме милек хуҗасы билгеләгән зыян күләменә бәйле булачак.

Шунысын да истә тотарга кирәк: җәнлек хуҗасын да автомобильгә китерелгән зыянны каплауга җәлеп итәргә мөмкин. Мәсәлән, әгәр юл-транспорт һәлакәте гомуми файдаланудагы юлда булган икән, димәк, хуҗа кеше үзенең йорт хайванын тиешенчә тотмаган, шул рәвешле ул юлга чыккан. Монда бит хуҗаның да гаебе бар дигән сүз.

Машина йөртүче колагына



✓Машина йөртүчеләр тиешле тизлек режимын сакларга һәм юл билгеләренә игътибарлы булырга тиеш. Бигрәк тә кичке-төнге сәгатьләрдә, күз күрүе начар булган вакытта.

✓Каршыгызга кыргый хайван чыкса (әйтик, поши), тавышланырга, сигнал белән куркытырга тырышмагыз, машина фарасы белән яктыртмагыз. Хайваннар моны киресенчә аңларга һәм сезгә һөҗүм итәргә дә мөмкин.

✓Юл бик тар булса, җәнлекне урап узам димәгез. Кире борылып китсәгез генә.

✓Ашыгыч рәвештә тормозга басу бик куркыныч. Аеруча кышын.

✓Җәнлекне бәрдергәнсез икән, аны машинага салып, каядыр алып китәргә тырышмагыз. Хокук саклау вәкилләре моны браконьерлык дип кабул итәргә мөмкин. Бу үзегезгә дә өстәмә мәшәкатьләр китерәчәк. Җинаять җаваплылыгы, арест, акчалата штрафтан котылып булмаячак.

✓Хайваннар машинаның нинди тизлек белән хәрәкәт итүен белә алмый. Кайбер вакытта кыргый җәнлек юл уртасында туктап калырга да мөмкин. Әйтик, боланнар һәм пошилар. Әгәр хайван хәрәкәтләнми икән, димәк, ул урманнан баласы чыгуын көтә. Аларның узып китүен сабыр гына көтеп тору сорала.

ӘЙДӘ ТАУЛАРГА!

«ВТ» ЖУРНАЛИСТЫНЫҢ ЯЛ ИТКӘНДӘ КҮРГӘННӘРЕ

4 КЕШЕЛЕК ГАИЛӘГӘ 10 КӨНЛЕК СӘЯХӘТ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

- **4500** чакрым юл үтелгән. **14** мең сумлык бензин салдык.
- **5** кунакханәдә куну өчен **38** мең сум түләдек.
- Ашау уртача **65–70** мең сумга төште.
- Экскурсияләргә **20** мең сум тоттык.

Мин болай да Ватанын яратучы кеше идем. Әлегә кадәр туган ягым, туган авылымнан да кадерле җир тапмадым. Ә менә җәйге ялда гаиләбез белән машинада каядыр барып кайтуны күптән гадәткә керттек. Ике мәртәбә Кырым якларында үз хутыбыз белән ял итеп кайткан идек инде. Быел маршрутны алдан төземәдек. Без юлга җыенган көннәрдә җылы якларга илтүче юллардан шомлы хәбәрләр дә килгәләде. Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, юлга кузгалдык...

Кисловодск

Күңелемдә бу шәһәрне барып күрү теләге кыш аеннан бирле яши иде инде. Хезмәттәшем Зөлфия Хәлиуллина да, сәфәргә кузгаласыбызны белгәч, Кисловодскига керми калмагыз, дип киңәш бирде. Казаннан иртәнге дүртенчедә чыгып киттек. Әкренләп таң беленә, кояш чыга. Кешеләр әле тәмле йокысын туйдырган мәлдә, син кояшның нурларына чумып, еракка юл тотасың. Иге-чиге күренмәгән юлдан барган саен нидер өмет итәсең. Үз ягында игътибар да итмәгән сары көнбагышлар да бик матур булып күренә.

Кичке алтыларда без Волгоградта идек инде. Шул якларга барганда туктала торган кунакханәдә танып ук торалар. Бу юлы алдан хәбәр бирмәсәк тә, урыннар бар иде. Иртәнге 3тә янә юлга кузгалдык. Волгоградның теге ягы безнең өчен яңа маршрут иде.

Кояш бик кыздырганчы дип барырга тырышабыз. Юлда очраган азык-төлек кибетеннән ашарга-эчәргә алып, ашханәдән термоска чәй салып чыккан идек. Тиз генә туктыйсы итмәдек. Навигатордагы татар кызы безне Элиста шәһәре аша алып китте. Калмыкия Республикасын аркылыга-буйга иңләдек. Авыллар аша бардык. Анда юл буе сыер көтүе. Дөяләр дә көтүлектә йөри. Авылларында мәчетләр күренә. Бара торгач, Ставрополь өлкәсенең Благородное шәһәренә килеп чыктык. Биредә ашарга туктадык. Бик матур кафе таптык, ял итеп алдык та тагын юлга кузгалдык. Инде таулар күренә башлады. Ничек тә тизрәк Кисловодскига барып җитәсе килде. Кичке биштә инде үзебез яшисе кунак йортында идек.

Бу шәһәрдә күңелгә тынычлык таптык без. Килгән көнне үк өс-башларны алыштырып алгач, шәһәргә чыгарга уйладык. 1900 километр ара узганны онытпык та. Рәхәт җиргә килеп кердек. Элеккеге заманга эләгәсең монда. Кешеләр дә үзгәрмәгән, ашханәләр дә шул килеш. Бер-берең ярдәм итәргә атлыгып торучылар күп.

Иртәгәсен инде шәһәр буйлап йөрүебезне дәвам иттек. «Чебурашка» фильмы төшерелгән урыннарны карадык, нарзан сулары чыккан җирләрне күрдек, биеклеккә күтәрелдек. Роза гөлләре басуында булдык. Паркны бик ошаттык. Андагы чисталык, тәртипкә сокландык. Иң биек ноктага менеп, тирә-якны күзәттек. Канат юлы буенча уздык.

Биредә үзәк урамнарда бушлай шифалы сулар агып утыра. Күпме телисең, шулкадәр эчәргә ярый, үзең белән алсаң да, сүз әйтүче юк. Су эчүчеләрне күргәч, урамда ике ханымның сөйләшкәнен дә ишеттем. «Кешеләр ерактан килеп эчә, безнең вакыт юк», – ди алар. Шулай инде ул, күршенең тавыгы да күркә булып күренә бит.

Икенче көнне тур алып, тагын да матур җирләрне карарга киттек. Без сайлаган маршрут Карачай-Черкес Республикасы аша үтә иде. Тауларга да мендек, чәй йортын да карадык, баллы шарлавыкка да бардык.

Гаилә архивыннан

Бу якларда халыкның бигрәк тә ачык, ярдәмчел булуын ошаттык. Татарча сөйләшкәнне белеп, алар да безнең телгә күчә. Тау битләрендә сату итүче апалар аеруча безне үз итте. Шәл, төрле киемнәр бәйлиләр икән. Рәхәтләнеп, бер бозмыйча татарча сөйләшүләренә сокландым. Инде чәй йортына баргач, андагы кешеләрнең дә татарча җавап бирүләре сөендерде. Әле ул гынамы, алар безгә зур-зур ташламалар да ясадылар. Үзләре сата, үзләре бәйләп утыра алар. Ул апаларны сөйләштерәм. Туристлар ярдәме белән акча эшләп калалар икән. Авылларда эш юк. Күпләп мал тотып, тормыш көтәләр. Әмма бер дә зарланмыйлар. Булганына шөкер, диләр.

Турист булып йөргәндә, Татарстанда эшли ала торган эшләрне дә барладым. Әйтик, карачай халкы баллы шарлавыкка килгән туристларга үзләренең милли киемнәрен киеп фотога төшү мөмкинлеге тудырган. 4–5 төрле күлмәк элеп куйганнар. Бәясе дә кыйммәт түгел – 100 сум. Шулай ук атка атланып, милли киемнәр киеп, фотога төшәргә була. Бәясе шул ук. Шунда ук зоопарк та бар. Керү бушлай. Ашатыр өчен 50 сумга азык кына сатып аласы.

Өченче көнгә Суворов термаль суларын да күреп кайтырга насыйп булды. Кешеләр файдасын бик күрә икән. Безгә дә ошады. Бу якларга килгәч, Ессентуки шәһәренә дә кереп чыгарга булдык. Аның да матур җирләрен күреп, тәмле суларын эчтек.

Грозный

Кисловодскига килеп урнашуга, Грозныйда бер көнгә кунакханә белешеп куйган идек инде. Бу шәһәрнең матур җирләрен, дөресрәге, мәчетләрен күрәсе килде. Башка җирләрдә кунакханәгә минем генә паспортны күрсәтеп керсәк, Грозныйда бөтенләй башка таләп. Һәрберебезнең паспорты, пропискасы кирәк. Балаларның безнеке икәнен дә раслыйсы.

Грозный бик зәвыклы, затлы шәһәр булып истә калды. Кешеләре дә горур аның. Алдан ук киенү рәвешебезне кайгыртып баргач, безгә кыен булмады. Дөрес итеп киенгәч, чеченнар да елмаеп кына торалар. Хәер, арада ярым шәрә туристлар да бар иде. Әхмәт Кадыйров исемендәге «Чечня йөрәге» мәчете бөтенләй сихерләде. Без аны бик яраттык. Биредә мәчетләр затлы, кыйммәтле һәм зур. Акчаны кызганмыйча төзегәннәре күренеп тора. Төн җиткәнче Грозный урамында хозурланып йөрдек. Милли ризыкларын авыз иттек. Шулкадәр тәмле алар!

Махачкала

Ике шәһәр арасын 3 сәгать барасы. Моңа кадәр гел тигез юлдан, тәртип белән йөргәч, биредә дә шулайдыр, дип уйладык. Тик машина йөртүчеләргә шаккаттык. Монда берәү дә берәүгә юл бирми, уздырмый. Һәр кешенең – үз юлы, үз тәртибе. Инде светофорда яшел ут янды дисәң дә, әллә каян берәр машина килеп чыгып, юлыңа каршы төшеп, бөке ясый. Безнең өчен Махачкалада йөрү аттракционда атынуга тиң булды. Шулай да, сер бирмәдек, базарларын, матур мәчетләрен, кайбер кибетләрен йөреп чыктык. Әле ярый, яшисе урынны ерак китмичә, Махачкаладан 14 чакрым ераклыктагы Каспийск шәһәреннән сайлаганбыз, дип шатландым.

Безне биредә үз туганын көткәндәй фатир хуҗасы Зөһрә каршы алды. Без аны интернет аша тапкан идек. Монда урнашкач, иркен сулап куйдык. Кая барырга, кайсы пляжда коенырга, кайда ашарга икәнен, нинди кибеттә нәрсә сатканнарын Зөһрәбез аңлатып бирде. Үзе дә 14 ел Казанда яшәгән икән. Безне бик якын итте. Сөйләшеп сүзләр бетмәде аның белән. Ул бездәге матурлыкны сөйли, без аларда күргәнне уртаклаштык.

Каспий диңгезенең чиста, тыныч вакытына туры килдек. Пляжның түләүлесен сайладык. Анда чистарак һәм ышанычлырак. Диңгез суының җылылыгын белсәгез! Рәхәтләндек кенә. Кояшы да баш өстендә генә. Комлыкта татарлар да бар иде. Түбән Камадан һәм Казаннан килгән гаиләләр белән дуслаштык.

Икенче көнне көнебез Сулак каньонында узды. Аңа илткән юл өстендәге авыллар тормышы белән танышып та алдык. Аларда да шул ук проблема: яшьләр шәһәргә китә, авылларда өлкәннәр яши. Тырышалар әле үзләре. Яшермиләр, туристлар акчасына көн күрүчесе күп. Бакчаларында үскән шәфталуларны килолап түгел, тартмалап саталар. Килосы 150 сум.

Сулак каньоны искиткеч матур! Яңгыр да берәүне дә куркытмады. Халык рәхәтләнеп фотога төшә, тәмле ризыклар белән сыйлана. Адым саен үзләренең милли ризыклары чудуны саталар. Аны сыр белән дә, эремчек белән дә, ит белән дә пешерәләр икән. Бездәге кыстыбый инде бу дип кайттым. Әмма аларныкы тәмлерәк. Сулак буенча катерларда йөрергә була. Бер йөреп килү – 5 мең сум. Егетләр бәяне төшерергә дә мөмкин. Әмма 4 меңнән дә түбән итмиләр. Һава торышы көйсезләнеп торгач, без катерда йөрмәдек.

Юлда тәртипсез йөреп куркытсалар да, Дагыстан халкын яратып кайттык. Аларның ит ризыкларын башка берәү дә кабатлый алмыйдыр, мөгаен. Хатын-кызларының ягымлы, ярдәмчеллегенә дә шаһит булдык. Сораган җирне аңлатып бирәләр. Казаннан булуыбыз барысына да ошады. Күбесенең безгә килгәне бар. Кайберләренең туганнары монда яши. Киленнәре Татарстанныкылар да бар.

Ошамаган ягы да бар – урамнарда чүп күп. Калдыкларны вакытында алып китмиләр. Ул бик начар ис таратып ята. Тагын бер кимчелек – урамда эт күп. Мәчеләр дә бихисап.

Төрле республикалар аша узарга туры килде. Юлларда ЮХИДИ постлары аша уздык. Дагыстанга барып җиткәнче берәү дә туктатмады. Бары тик кайтыр юлда, Чечня белән Калмыкия чигендә полиция хезмәткәре туктатып, башта документны, аннан багажникны тикшерде һәм теркәлү узуыбызны сорады. Ул 5 минутка да сузылмады.

Кайда гына йөрсәм дә, мин өемне, Казанымны сагындым. Машинадагы навигаторыбыз да татарча сөйләп йөрде, татар җырлары тыңладык. Инде барган җирләребездә дә татар булганыбызга горурланып кайттык.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Быел Роберт Миңнуллинсыз беренче юбилеен үткәрәбез. Исән булса, аңа 75 яшь тулган булыр иде. 3 ел элек каты авырудан соң халык шагыйре бакыйлыкка күчте. Якыннары, дуслары, иҗатташлары, якташлары аны сагынып искә алды, истәлекләре белән бүлеште.

САГЫНУ

Мулла абый

«Роберт абый безнең гаиләдә өчен генә түгел, нәселебездә мулла абый иде». Галим, шагыйрьнең энесе **Ким Миңнуллин** абыйсын әнә шулай искә алды:

– Роберт абый нәселдә үз буынының иң өлкән баласы булды. Шуңа күрә микән, белемгә омтылучанлыгы өченме – аны малай вакыттан ук мулла абый дип йөртәләр иде. Бу исем район газетасында эшләгәндә тагын да ныгыды. Ул инде нәселдә генә түгел, авыл халкы, хәтта ки күрше-тирә авыллар өчен дә укымышлылык үрнәге иде. Роберт абый редакциянең мотоциклында язма әзерләргә кайтса, муенында башкалар күрмәгән яхшы фотоаппарат булыр. Аның фотоаппарат белән дуслыгы гомер буе дәвам итте. Ул объектив аша башкалар күрмәгәнне күреп ала һәм «эләктерә» белде. Шагыйрьлеге фотоларында да күренде. Шушы сыйфаты аны рәссамнарга якынайтты. Рәссамнар дөньясына тартыла, алар белән әңгәмәләр корырга ярата иде. Роберт абый нәселебезне радиодан гына ишетеп белгән, телевизор аша гына күргән Казан каласына китүе, анда югары уку йортына керүе белән дә сокландырды. Авылга кайткач, ул әнкәйгә Казан турында сөйли, әнкәй йотлыгып тыңлый иде. Төннәр буе сөйләшеп чыга иде алар. Әнкәйнең: «Сезнең белән мин дә үстем, балалар», – дип әйткәне истә. Чөнки Роберт абый әнкәйне язучылар, артистлар белән таныштыра, тора-бара алар Роберт абыйдан башка гына да, үтеп барышлый әнкәйнең хәлен белергә керергә гадәтләнде.

...Ә бит абыйга бик иртә олыгаерга туры килде. Әткәй мәрхүм булганда, аңа – 11 яшь, миңа 11 ай булган. Үсмер чагында ул инде безгә олы абый булды, безне үзе тирәсендә укмаштырды. Әнкәй, әткәй вафатыннан соң, итәк тулы бала белән авылда кала, Роберт абый шул чакта, бала гына булса да, аның таянычына әйләнә. Шәһәр тәрбиясе алган, ятимлектә үскән әнкәйгә баштагы мәлләрдә бик авыр булгандыр, мөгаен. Ә Роберт абый аның бөтен кичерешләрен үзе аша үткәргәндер. Юкса каләме белән әнкәйләргә мәһабәт һәйкәл сала алмаган булыр иде.

Бер кызык хәлне дә сөйлим әле. Роберт абый, 8 нче сыйныфтан соң, әнкәй киңәшен тотып, кулинария училищесына укырга керә. Укуны дәвам итәргә авылда урта мәктәп булмау хикмәте дә инде бу. Мәктәпнең иң якын дигәне дә 30 чакрым ераклыкта урнашкан иде бит. Шуннан әни газетада белдерү күргән дә Роберт абыйга кулинария училищесына барырга әйткән. «Берәр ресторан директоры булып китәр дә әйбәт тормыш итәр, дип уйладым», – дип, көлеп сөйли иде соңыннан. Әнкәй, ятимлектә калып, балалар йортында яшәп алган һәм шәһәр тормышын бала күзлегеннән матур тормыш дип аңына сеңдергән. Ләкин Роберт абый училищеда калмады, Карабаш мәктәбендә 9 нчы сыйныфка укырга керде.

Минем өчен абыйлы булу зур җаваплылык булды. 15 яшемнән абый артыннан Казанга килдем һәм нинди генә эш яки гамәл ниятләсәм дә, үз-үземә «Абый килештерерме?» дигән сорау бирдем. Хәзер дә шулай. Юксынабыз сине, абый...

Әтисез беренче юбилей...

Кызы **Таңсылу Миңнуллина** истәлекләрен, әти белән безнең арада булган мөнәсәбәтне тасвирлар өчен сүзләр дә табып бетерә алмыйм, дип башлады:

– Миңа «Ул нинди әти иде?» дигән сорауны еш бирәләр һәм мин аңа төгәл җавап таба алмыйм. Китапларда язылган әти белән бала арасындагы иң яхшы мөнәсәбәтләрдән дә яхшырак дәрәҗәдә иде дип әйтергә була. Бәлки, бөтен бала да әтисе турында шундый фикердәдер, үзенең генә әтисе иң якын, иң кадерледер. Әмма субъективлыктан чыгып, объектив караган очракта да, мин аның белән шәхес буларак та, иҗат кешесе буларак та, әти буларак та һәрвакыт горурланам, сокланам. Нииндидер кимчелекле ягы бар иде дип тә әйтә алмыйм хәтта. Бу әтине югалтудан соң гына барлыкка килгән хисләр түгел. Бу тормыш дәвамында шулай булды. Мин 35 яшемдә әтисез калдым. Һәм 35 ел буе һәрвакыт уңай яклары гына белеп килдем. Миңа карата булсынмы, әнигә, оныкларга, гомумән, кешеләргә, тормышка карата булган принципларына соклана идем. Аның тормышка карашы үзенчәлекле, ихлас иде. Ул бөтен кешегә дә бирелә торган әйбер түгел. Кеше төрле халәттә булырга мөмкин. Иң кәефсез чагында да, бүлмәсенә кереп, китап актарып, тыныч кына утыра иде. Күз алдына китерәсезме: кешенең иң кәефсез, бәлки борчулы, бәлки нервланган чагы, ә ул бәрелми, сугылмый, акырышка җиткерми, фәкать ялгыз калып китап актара, я булмаса чыгып китә. Аның шушы гамәлләре үрнәк, тәрбияви маяк булды. Шуңа күрә нинди әти дигәндә, мин хәтта китап язып та җавап биреп бетерә алмас идем. Аның кадәр әти... шулай дип әйтим инде... тагын бармы икән ул?

Мин үземне белгәннән бирле өйдә һәр биш ел саен әтинең юбилеен үткәрү турында ярты ел алдан сөйләшә башлый идек. Аннары гөрләп, ярты елга сузылган бәйрәм чаралары үтә. Концерт, очрашулар, бәйгеләр – без шуның белән ярты еллап янып яши идек. Аннары һәрбер юбилей чарасына әти, чыгыш яса әле, дип әйтә иде. Хәтерлим, 45 яшьлек юбилеенда Опера театрында мин иң беренче тапкыр чыгыш ясадым. Әле ул чакта мин, 2 нче сыйныф укучысы, «Әйләнбәйлән» җырын башкарган идем. 50 яшьлегенә Камал театры сәхнәсендә башкорт биюен биедем. 60, 65 яшьлегендә, әтигә багышлап, үзенең җырларын җырладым. Гәрчә җырчы булмасам да. Соңгы юбилеенда, 70 еллыгында, әтинең бәләкәй кызына да 35 яшь бит инде, дип кыенсынып, чыгыш ясамый калдым. Хәзер инде менә әтисез, күңелсез беренче юбилейны үткәрәбез.

Узган елны Роберт Миңнуллин исемендәге Татар әдәбиятына һәм сәнгатенә ярдәм фонды үзенең эшен башлап җибәрде. Аның эшчәнлеге беренче чиратта Роберт Миңнуллин исемен яшәтүгә, аның иҗади мирасын саклап калуга юнәлтелгән. Юбилей чараларына килсәк, ул туган ягы Илеш районында башланып китте, бик матур тантаналы чара узды. Ел башында фонд Роберт Миңнуллин исемендәге китапханәдә «Шигърияткә сәяхәт» дип исемләнгән балалар бәйгесе узды. Дәвамлы булсын иде. Шундый бәйгене олылар өчен дә оештырасы килә. Чөнки Роберт Миңнуллин иҗатына сусаучылар күп, шушы чараларда катнашырга теләүчеләр күп. Алар миңа социаль челтәрләр аша да бик күп яза. Әтинең иҗаты шул юл буйлап сүрелмәскә тиеш дип уйлыйм. Көзгә таба юбилей чарасы уздырырга планлаштырыла, матур бер кичә булыр дип көтәбез. Шулай ук фәнни-гамәли конференция булыр дип ниятләнгән. Чаралар күп, тик алар юбилей елы белән генә чикләнмәсен иде. Әтинең хатлары, фотолар, истәлекләре бик күп, алар бик таркау, аларны җыю, архивны тәртипкә китерү өстендә эш алып барабыз. Ул бик кирәкле эш дип саныйм мин. Районнарга чыгып китәсе, әтинең иҗатын халыкка тагын да якынайтасы килә.

Тыйнаклык

«Беренче күрешүдән үк тыйнак егет булып истә калды». Журналист, җәмәгать эшлеклесе **Римзил Вәлиев** шагыйрьне шулай искә алды:

– Ул 1966 елда Башкорт дәүләт университетына укырга кергән вакытта ук мөлаем, тыйнак егет булып истә калды. Керү имтиханнарының берсе рус теленнән изложение язу иде. Шуннан аз гына баллы җитмәде аның. Илешкә кайтып, район газетасына эшкә урнашты. Бер ел эшләп тәҗрибә туплаганнан соң Казанга укырга китте. Бераздан матбугатта шигырьләре чыга башлады. Күп еллар үткәннән соң, мине «Комсомольская правда» газетасынның корреспондент итеп Казанга җибәрделәр. Ул чорда миңа Госман Садә, Роберт ярдәм итте. Ярдәмчел иде ул. Ул вакытта инде ачылган, зур талант иясе булып танылган, ләкин тыйнак булып калган иде. Бер караганда, әнкәй темасы кат-кат язылган, тапталган тема бит инде, ә ул Әнкәй образын нинди биеклеккә күтәрде! Аннары балалар шигърияте белән шөгыльләнде һәм ихласлыгы белән бөтен балаларның игътибарын үзенә туплады. Роберт тыйнак кына, әтәчләнмичә генә үсте дә үсте һәм зур, мәһабәт шәхескә, зур шагыйрьгә әйләнде. Депутат эшчәнлеген алыйк: Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе, Дәүләт Советы рәисе урынбасары – ул бит бу эшендә дә ихласлыгы, тыйнаклыгы белән үзенә ышандыра белде. Халык аңа ышана иде. Мин аңа

«Дустым, синдә нәрсәдер бар кебек,
Әллә талант, әллә сабырлык.
Кем уйлаган шушы тыйнаклыгың
Синдә кәсеп булып калыр дип...»

дигән шигъри пародия, эпиграмма яздым. Ул аны кабул итте, үпкәләмәде. Димәк, сәламәт рухлы булган. Әлбәттә, Роберт җитми заманга. Ә бит спортта, бизнеста, шигърияттә, әдәбиятта, мәдәнияттә көндәшлек, ярыш бар. Ул шул ярышта сабырлыгы белән өскә күтәрелде.

Әй, бу вакытның үтүләре...

Якташы, җырчы **Айдар Галимов** соңгы күрешүләрен хәтерендә яңартты:

– Әй, бу вакытның узулары... Тагын август аена кереп барабыз икән бит. Роберт абый, якташым онытылмый, сагындыра, күңел кылларын сызлатып, сызлатып искә төшә. Хушлашканда, кызы Таңсылуның сүзләре йөрәккә үтеп кергән иде, әле дә колакта чыңлап тора. Зәңгәр күкләргә карап көтәрбез, сагынырбыз инде без сине, дигән иде. Менә шулай инде, сагынып яшәргә калды. Кайчак исә Казанга барырбыз да күрешербез кебек, кайчак Уфага килеп чыгар кебек. Ул бит ике кала арасын якынайтып торучы шәхесләрнең берсе булды. Актив тормыш алып барды, гел халык белән аралашып яшәде. Мин аның бик күп җырларын башкардым, тагын да башкарырга насыйп булсын. Башкарылмаган җырларым да бар, алар аның алдында бурыч кебек тора. Ике яңа җырым һаман әле дөнья күрмәгән. Берсен ул исән чакта туган авылы Шәммәттә җырладым, ә менә язмасы һаман да әле язылмаган. Аның исемен ишетү белән, мыек астыннан гына елмаеп торуы күз алдына килә. Киңәшләрен бирер, турысын әйтер иде. Мактаса мактар, тәнкыйтьләсә тәнкыйтьләр. Үзенә дә минем дустым, абзыем, якташым, тәнкыйтьчем дип тә әйтә идем. Якын итеп, яратып. Тәнкыйтьчеләрне гадәттә яратмыйлар, аны яратмыйча булмый иде. Әйткән сүзе гадел булгач, ничек яратмыйсың инде?.. Аңа бәйле хатирәләр күп, алар арасында иң ягтысы бергәләп туган якларны әйләнү булгандыр. Мин рульдә, ул минем янымда. Бишбүләк, Миякә, Акмулла, Фатих Кәримнең туган авылында булдык... Моңа сөенеп туя алмыйм, ярый шуңа өлгергәнбез әле, дим. Шул чакта аның чын-чынлап халык шагыйре икәнен аңладым. Күңелем бер нәрсәгә тыныч: соңгы юбилей программама Роберт абыйны чакыра алдым һәм ул килде. Концертны башыннан ахырынача карап утырды. Аның «Әнкәләр-тупыллар»ын җырлаганда, залга төштем, күрештек, кочаклаштык. Якыннан күреп, соңгы кочаклашуыбыз булган икән. Халык арасында, җыр аша күрешеп хушлашканбыз. Роберт абый гаилә җанлы кеше иде. Клара апа, балалары, оныклары дип яшәп торучы, үрнәк кеше. Аның туган авылына, әнисенә, иленә, теленә булган мөнәсәбәтен әйтеп аңлатырлык түгел. Шундыйлар безне данлый да, тарихта эзле итеп калдыра да инде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Моң

Роберт Миңнуллинның шигырьләре саф та, ягымлы да. Алар кайсы ягы беләндер назлы җилне хәтерләтә. Шигъри сөйләме җил кебек йөгерек – бер җирендә абынып-сөрлегеп тормассың. Укыганда да алар кемдер язган шигырь түгел, ә табигый рәвештә үзеннән туып, үзендә яшәгән уйлар-кичерешләр агышы булып тоела. Табигый моң.

Ул моң ургылып та, ташып та түгел, ә сабыр гына саркылып чыга. Аны тыеп-туктатып та, ашыктырып та булмый. Кирәкми дә. Ул шул килеш тә дулкынландыра, ә үз җанындагы әрнүләр белән кавышканда хәтта елата да ала. Елатса да, юатса да, бу моң яраламый. Киресенчә, ягымлы бер дулкын булып җаныңны назлап уза, авыр тойгыларыңны оныттыра. Шул рәвешле сиздермичә генә, сине авыр уйлардан тартып алып, яктылыкка алып чыга.

Бу сыйфат, мәхәббәт лирикасына гына түгел, аның бөтен иҗатына кагыладыр. Миңа калса, Роберт Миңнуллинның шигырьләрен кычкырып яки трибунадан йодрык болгап укып булмыйдыр. Алар – табигый үз тавышың белән укый торган шигырьләр. Сөйләшеп утыргандагы кебек. Алар шул килеш тә ерак ишетелә. Табиб кулыдай сак, дипломат сүзедәй итагатьле.

Язганнар язды бездә дә,
Менә дигән итеп.
Әйбәт заманнар килгәнне
Ятмадылар көтеп.

Шул ук вакытта, тәвәккәл, үтемле, кире каккысыз:

«Шигырьләрең бармый», – диеп,
Хәзер беркем бормый.
Шәп шигырьләр язу җиңел –
Язып кына булмый.

«Язганнар язды бездә дә» дип аталган бу шигырьне укыгач, елмаеп та куясың. Мондый әсәрләренең күплеген искә алсаң, авторны «кызык шагыйрьләр» рәтенә кертергә дә мөмкин кебек. Әмма шигырьдә сүз нәрсә хакында барганын уйласаң, бер дә елмаясы килми. Һәм шагыйрь күңелендәге әрнүләрне үз җаныңда кичерергә мәҗбүр буласың. Ә шушы шигырь тәэсирендә әдәбиятыбызның бүгенгесе, киләчәге хакында чиксез уйлануларга бирелергә дә, озаклап бәхәсләр корырга да мөмкин. Бу бүгенге шигърияткә куелган диагноз шикелле дә яңгырый. Үземнең дә шундыйрак халәт кичергән чакларым күп:

Шәп әсәрләр язу җиңел –
Язып кына булмый.

Ул иң әрнүле проблемалар турында да якты каләм белән яза. Шигырь юлларында хәтта моңсу елмаюы да чагылып киткәндәй була. Елмаюы да, моңсулыгы да табигый. Күз яшьләре кебек үзлегеннән саркып чыга торган. Үз моңың шикелле. Үз моңың, үз сагышың булып аның тагын бер шигыре күңелдә өзгәләнә:

Сандугачлар китә инде,
Кала моңнары гына.
Моңнарының күңелләрдә
Кала торганы гына.

Марат КӘБИРОВ

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

< Дәвамы. Башы 14, 21, 28 июль саннарында

Бу сүзләрдән кыз тагын да ныграк коелып төште. Лена, аңа карап:

– Әй, елый да туктый бит ул Катя апа. Әйдә, уйныйбыз, – диде дә Гөлсәйдәнең кулыннан тартып, үзенең уенчыкларын күрсәтергә тотынды. Кызлар уен белән мавыккан арада Зина апа өстәл өстендә җитез генә камыр басып алды, аннан түгәрәкләр ясап тезеп куйды. Аларча крендель дип атала икән. Гөлсәйдәнең исендә әле, әтисе калага баргач, бауга тезелгән шушындый түгәрәкләр алып кайткан иде. «Крантил» дигән ул зур түгәрәкләр чынында, Зина апа әйткәнчә, крендель булган инде...

Бераздан шушы кечкенә бүлмә эчендә, кояш исе, муллык исе, яшәү исе булып, ипи исе таралды – капкачы ябылган мичтә, авыз суларын китереп, көлгә тезелгән «крантил» пешә иде. Гөлсәйдә белән Лена, утын пүләненә яулык бәйләтеп, курчаклы уйнаган җирләреннән әледән-әле мич ягына борылып карадылар. Зина апа, моны сизеп, сагышлы гына көлеп куйды.

сәйдәдә уен кайгысы калмады. Аның баш миендәге һәр күзәнәкне, һәр сырны кесә төбендәге ярты сынык икмәк биләп алган иде. Кыз кайтырга җыена башлады. Тик Ленаның нигәдер ачуы килдеме, ахирәтенә үпкәләдеме, тамак төбен кытыклап кына куйган ризык ярсытып җибәрдеме – Гөлсәйдәне җибәрергә теләмәде, аның кулын эләктерде дә:

– Без әле уйнап бетермәдек, тагын уйныйбыз! – дип, аңа ирексезләп курчакны тоттырды.

Ләкин Гөлсәйдә, курчакны ыргытып, ашыга-ашыга үзенең киез итеген киеп куйды.

– Мин кайтам, дом, дом, – дип урысчалап аңлатырга маташты да башына шәлен бәйләп, сырмасына үрелде.

Ленаның күзләре ачулы ялтырап китте. Ул ике куллап Гөлсәйдәнең сырма итәгенә ябышты.

– Алайса кренделне бир! Ул синеке түгел, ул безнеке!

Көтелмәгән сүзләрдән Гөлсәйдә өнсез калды. Ничек инде?.. Дөнья кинәт караңгыланып китте, кыз, Зина апа килеп кер-

– Пеште, пеште, балакайлар, хәзер сыйлыйм үзегезне. – Шулай диде дә кулына бияләй киеп, мич капкачын ачты, үзе дә борын канатларын киереп, хуш искә исереп торды.

Бераздан кызарып пешкән кренделләрне сөлге өстенә алып салды, дөньядагы иң зур байлыкка ия булгандай, йөзендә әйтеп бетергесез бәхет нуры балкытып, күзләрен йомды да иреннәрен ачар-ачмас кына нидер укынып алды. Бер кренделне, ватыла торган кыйммәтле нәрсә урынына күреп, кадерләп кенә кулына тотты, көлен коеп, урталай сындырды да күзләрен мөлдерәтеп торган ике кызга ике кисәк сузды.

Гөлсәйдә башта Зина апа кулындагы ризыкка үрелергә кыймады. Бу бөтенләй кеше ышанмаслык бер хәл булып тоелды. Аңа, берүзенә, чып-чын оннан пешкән, кызарып, ымсындырып торган ипи сыныгы бирәләр!

– Бери, бери! Ал, балакай, аша! – Зина апа кызның оялуын күреп, аркасыннан кагып куйды. – Кыенсынма, ал!

Исе үк исертерлек ризыкны кулына алгач, Гөлсәйдә тагын югалып калды. Шушы кадәр байлыкны хәзер берүзе ашап бетерсә, әнисе белән абыйсының күзенә ничек карар?..

– Катя апагызны карап керим әле, кая югалды икән? Аннан бергәләп чәй эчәрбез. – Зина апа, затлы ризыкны сөлгегә төреп куйды да тиз-тиз киенеп, тышка чыгып китте.

Гөлсәйдә исә, кулындагы кадерле күчтәнәчне, тел дә тидермәгән килеш, сырма кесәсенә салып куйды. Аның тизрәк өйләренә чыгып йөгерәсе, шушы байлыкны исән-имин алып кайтып җиткерәсе, әнисе белән абыйсын шатландырасы килә иде. Кесәсендәге бу ризыкның барлыгын белеп тору гына да кызның күңелен алгысыта, авызыннан сулар китерә иде. Бер генә чеметем... бер генә чеметем тешләп караса... Аһ, нинди хуш ис, нинди татлы, нинди тәмле!.. Башларны әйләндерә, күңелне канатландыра, җанны иләсләндерә!

Кызның уйлары шул крендель кисәгеннән ерак китә алмады. Ул хыялланып утырган арада үз өлешен җитез генә ашап бетергән Лена төрелгән сөлге ягына нәүмиз караш ташлады, авыр сулап, агач курчакны янә кулына алды. Тик Гөлмәсме дип, өмет тулы күзләре белән ишеккә борылып карады.

– Бир кренделне! Бир диләр сиңа! Попрашайка!!!

Әлеге сүзне тәүге тапкыр ишетсә дә, Гөлсәйдә аның кимсетү сүзе икәнен бар вөҗүде белән аңлап алды. Тамак төбен авырттырып, каты бер төер килеп кысылды. Кыз тиз генә кесәсенә тыгылды. Әлеге төер булмаса, Гөлсәйдә, Ленага үч итеп, кренделне аның күз алдында ашап куярга теләгән иде. Тик бу мәлдә авызыннан ризык үтәрлек түгел икәнен сабый йөрәге белән төшенде.

– Мә! – Ныклап суынырга да өлгермәгән кисәкне, җаныннан өзеп биргәндәй, Ленаның кулына сонды да күзләренә кисәк китереп бәргән яшьне күрсәтмәс өчен, ишекне ачып, тышка атылды.

Кышкы көннең аклыгын урлап, иплән кенә эңгер иңеп килә иде. Гөлсәйдә, олы киез итекләренә абына-сөртенә, ферма тавына таба йөгерде. Каравыл өе күздән югалгач, кар өстенә сузылып ятты да күз яшьләренә иркенләп агарга ирек бирде. Кайнар яшь тамчылары бераздан бозга әйләнеп, керфек очларына ябышып катты, сырма якасын да боз сарды. Җан әрнүе, телгә эләкмәгән икмәк тәме, сугыш китергән ачлык афәте кызның йөрәген талкый, бәгырен өзгәли иде – әле йөзтүбән капланып, әле чалкан ятып, рәхәтләнеп елады да елады ул. Күңеле бушангандай иткәч, сырмасындагы карны каккалап, авырайган керфекләрен угалап, өйләренә торып чапты. Онытылып китеп, әллә ничә тапкыр кесәсенә үрелде – насыйп булмаган крендель үзе булмаса да, аның үзәк өзгеч исе шунда сакланып калган кебек...

Базда булган бәрәңге авыл халкына бу кышны исән-сау чыгарга ярдәм итте. Үләнле яз, җиләкле җәй исә – инде яшәү дигән сүз иде. Әниләре көне-төне колхоз эшендә булгач, өйне карау, дөнья көтү бала-чага өстенә өелде. Бер очта яшәүче Зәйнәп, Шәмсия, Гөлсәйдә, Асия гел дүртәүләп йөриләр, үлән җыярга чыксалар да, сызыклы уйнарга җыелсалар да, бер-берсен калдыру юк. Шулай да, апалы-сеңелле Зәйнәп белән Шәмсиягә, зуррак булгач, уенга чыгу артык тәтеми, әниләре Мәрфугага ияреп, эшкә дә баргалыйлар.

Беркөнне алар хатын-кызларның инеш буенда кирпеч сугуларын шулкадәр кызык итеп сөйләделәр, икенче көнне Асия белән Гөлсәйдә дә әниләренә ияреп барасы иттеләр.

Кызлар башта әниләренең эшләгәнен кызык итеп шым гына карап тордылар да тиз ялыктылар, чыр-чу килеп, яланаяк инешкә йөгерделәр.

Колхоз эшенә йөрүче хатын-кызлар инде өченче көн шушында кирпеч сугалар. Авылның каршы як тавында, аның да иң биек урынында яңа ферма төзергә җыеналар икән, шуның стенасын өяргә кирпеч кирәк.

– Якындарак урын беткән диярсең, җәһәннәм тишегендә төземәсәләр... – Чая теле белән аерылып торган Мәрфуга, күлмәгенең ямаулы җиңен терсәгенә кадәр сызганып куйды да балта алып, салам вакларга тотынды.

Чокырдан кызыл балчык ташыган хатыннар да, аның сүзен куәтләп, зарланышып алдылар.

– Әйтмә инде, малакаем, безнең ише кеше берүк рәхәт күрмәсен тагы ди торганнардыр. – Нәсимә, кисмәк хәтле чиләктән кызыл балчыкны калыпка бушаткач, алъяпкыч итәген әйләндереп, тирле маңгаен сөртеп алды.

Хәдичә, гадәтенчә, сүзгә кушылмый гына, инештән көянтә белән су ташый иде. Башкаларныкы кебек, аның да озын итәге балчыкка батып, пычранып беткән, яулык астыннан күренеп торган толымнары атлаган саен җай гына тирбәлә.

Төш уртасы җиткәч, чәй эчеп киләбез дип, хатыннар өйгә җыена башладылар. Гөлсәйдә белән Асия исә әниләре әбәдкә киткәндә дә инеш буенда пычырдап калдылар. Яланаяк килеш суга бер кереп, бер чыгып йөри торгач, зәңгәрләнеп беттеләр, шулай да өйгә кайтып китәсе килми иде. Яр буенда юеш комнан тау өеп, комнан кабартма «пешереп» мәш килделәр, бер-берсен кунакка чакырып «сыйландылар». Чын-чынлап ачыкканнары искә төшкәч, сикереп тордылар да, пыр тузып, кәҗә сакалы эзләргә тотындылар. Катып киткән булса да, кукы да ашамаслык түгел икән – биек үлән арасыннан байтак кына кукы өзеп алдылар, кәҗә сакалы җыйдылар.

– Иренеңә тигермә, җүләр, кабарып чыга бит! – Асия, ахирәтенең җиргә утырган килеш комагайланып үлән кимерүен болай да зур күзләрен тагын да түгәрәкләндереп карап торды да челтерәп көлеп җибәрде. – Кем инде үләнгә кәҗә сакалы дисен, вәт җүләр, әйме-е, Гөлсәй, – диде ул, «җүләр» дигән сүзне әллә ничә кабатлап. Аның алгы тешләре төшкән, яңалары чыгып җитмәгән, шуңа да кайбер авазларны мәзәк итеп әйтә иде. Гөлсәйдә дә, чырык-чырык килеп, Асияне ирештерде:

– Син үзең җүләр, кукыны әрчеми ашыйсың!

– Әй, болай тәмлерәк тә әле ул! – Асия чебиләп чыгарга өлгергән кул аркасы белән авыз кырыйларын сөрткәләде. – Әбекәй әйтә, сугыш кына бетсен, рәхәтләнеп әпәй ашарбыз, ди, менәтрәк бит!

– Ә без әткәйгә пасылкы җибәрдек! Кү-үп итеп тәмәке салдык, әнкәй мичтә эпи дә киптерде! – Шулай диде дә Гөлсәйдә моңаеп калды, әткәсенә җибәрергә дип киптерелгән алабута икмәгенең эчне айкаган исе борынына килеп ягылгандай булды, абыйсы белән икесенә эләккән берәр-берәр кыерчыкның әчкелтем тәме ашказанын кытыклап куйды.

Асия исә, үләнгә җәйрәп утырган җиреннән кинәт кенә сикереп торды да шәрә үкчәләрен ялтыратып, инешкә йөгерде. Сабый гына булса да, ул үзенең әткәсенең беркайчан да әйләнеп кайтмасын белә иде инде... Кызчыкның үтә күренмәле диярлек ябык гәүдәсе, шыр сөяк кенә булган кул-аяклары, нәзек муены җил чыңына өзелер кыңгырау гөлне хәтерләтеп, инеш суына иелде.

Дәвамы бар >

АГУСТ ИСЕ

- Август исе ул – тагын бер узган җәй исе.
- Вакытны бер сәгать алга күчергән кебек, җәйне дә бер айга артка күчерсеннәр иде.
- Икътисад белгечләре финанс мендәрен августтан ук хәстәрли башларга киңәш итә. Җәйге кием кесәсендә 100 сум «онытып» калдырып.
- Август ул елның якшәмбесе сыман: үзе ял да кебек, әмма күңел барыбер моңсу.
- Әни миңа баланы август аена туры китереп тудырырга киңәш итте. Ел саен туган көнен уздырырга җиңелрәк булачак, бакчада муллык бит.
- 31 август көнне кечкә тугызда балагызга портфель җыешырга онытмагыз.
- Августта моңсуланмагыз. Сентябрь җиткәч, «Их, мәнә августта ул әле җәй булган икән», – диячәксез бит.



vk.com

Әз-мәз мәзәк

Кара диңгезгә баргач, шуңа игътибар иттем: яз көне спортзалларда тырыша-тырыша фигура ясаган кешеләр быел ялга килмәгән.

* * *

Тизрәк баеп, «бәхет акчада түгел» дип, интервьюлар биреп йөрисем килә.

* * *

Бүген Россиядә миллионнарча халык урамнарга чыкты! Чөнки эшләренә барасылары бар иде...

* * *

Минем мәчем британ токымыннан. Аның аша виза эшләтеп булмас микән?



Сканворд җаваплары

Горизонталь: кала, арпа, Ренат, исән, чат, чебен, анда, Арча, Иске, Бану, куб, Лилия, Ык, арыш, ЗИЛ, ят, шаярту, кукы, Апас, шәлкем, аш, ал, таяк, ТАИФ, Барби, им, ым, СИБУР, АН, ашы, чана, Ырга, Емеля, Ка, карак, Львов, Аяз, Нури, Илгиз.

Вертикаль: чиләк, тире, урам, балык, ре, ышкы, Нияз, мая, Сафин, ирле, Алинә, акыл, чык, прәннек, Ает, айвори, каен, япма, ил, чабата, Исакова, Луара, ар, Сафина, яки, таныш, барраз, Рушан, бу, сарык, акыру, абага, Абдуллина.

Беләсең килсә...

1 «Дежавю» сүзенең кире мәгънәсе нинди сүз белән белдерелә?
а) җадевю;
б) жамевю;
в) межавю.

2 «Кот в сапогах» әкиятен кем язган?
а) Ханс Кристиан Андерсен;
б) Шарль Перро;
в) Астрид Линдгрен.

3 Кирпечнең иң зур ягы ничек дип атала?
а) постель;
б) ложок;
в) тычок.

4 Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров тумышы белән кайсы районнан?
а) Әтнә;
б) Актаныш;
в) Мамадыш.

Җаваплар: 1.б); 2.б); 3.а); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 311

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (**420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.**).

16+